Татарлар: кичә, бүген, иртәгә

БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫНЫҢ 30 ЕЛЛЫГЫ ҺӘМ VIII СЪЕЗДЫ УҢАЕННАН МАХСУС САН

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 109 (28882) | Шимбә | 30 июль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ТАРИХИ ХӘТЕРНЕ БАРЛАГАНДА

Бөтендөнья татар конгрессы оешуга – 30 ел. Бик күп вакыт та түгел кебек, тарих өчен ялтырап-чагылып киткән бер мизгел генә. Бәлки шуңа күрә моннан берничә дистә ел элек булган вакыйгалар турында «әле кайчан гына...» кебек сүзләр кыстырып сөйлибездер дә. Зур тарих исә әнә шул кечкенә тоелган мизгелләрдән барлыкка килә. Мизгелләр кеше күңеленә «үз тамгасы»н салып калдыра, борма-борма сырлар аша баш мие күзәнәкләренә кереп утыра.

Без күпме гасырлар узып та, татарның дәүләт тоткан халык икәнен искә төшерәбез, ерак тарихны «әле кайчан гына» булган вакыйга итеп күзаллыйбыз.

Олы максатка беркайчан да туры юлдан гына барылмаган. Сикәлтәле-бормалы булмаса, юл газаплары мәңге онытылмас булып күңел күзәнәкләренә урнашып та калмас иде. Татар үзен бөтен авырлыкларны җиңәрдәй көчле милләт итеп сизмәсә-белмәсә, «Шул халыкныңмы хокукка хакы юк?» – дип, бер-бер әшкә тотынмас иде. Бөтендөнья татар конгресссы барлыкка килү дә тарихи хәтернең әледән-әле яңарып торуына бәйле.

Гомумән алганда, «конгресс» сүзе латинчадан тәрҗемә иткәндә «җыелышу, аралашу» дигән мәгънәне аңлата. Дөньялар бутала башлаганда татарга да җыелышу, бергә укмашу кирәк иде.

Тарихта иң билгеле конгресслар (Париж конгрессы, Вена конгрессы, Берлин конгрессы) сугышлардан соң бер җыелып сөйләшү-килешү өчен уздырылган, алар да «трактат»лар кабул иткәннәр. Татар конгрессы исә канга батып сугышу белән түгел, ә СССР дигән зур держава таркалып, кайбер халыкларның «тату гаилә»не ташлап, «башка чыгу» омтылышына бәйле. Татар да үз йортында узенчә үз гаиләсен корырга хыялланды. Әммә Россиядән аерылып чыгу уе юк иде аның күңелендә. Чөнки ул килмешәк түгел иде, үз җирендә яшәде һәм яши.

Кешеләр арасында үткәннәрне генә хәтерләүчеләр бар. Андыйлар өчен хәзерге көн дә, киләчәк тә юк! Бу нинди авырудыр, исемен тәгаен генә әйтә алмыйм. Бары тик татарга шундый зәхмәт йокмасын иде, дим.

Кайсыдыр акыл иясе «үткәнне оныткан кешегә шул үткән тагын килер» дигәнрәк сүзләр әйткән. Бу үз вакытында хаталарыбызны күрмәсәк, танымасак, гыйбрәт алмасак, ул хаталар тагын кабатланачак дигән сүз инде. Шул ук вакытта кайбер галимнәр әйтүенчә, киләчәкне дә хәтердә калдырырга мөмкин икән. Кызык бит, ә!

Илдар Мөхәммәтҗанов

Димәк, без үткәнне истә тотып, хәзерге көннән киләчәккә карап яшәргә тиеш булабыз. Гомеренең соңгы көннәрендә кешенең хәтере бетә, ул бернәрсә дә белештерми башлый. Яшәү өчен баш миенең тере булуы, күзәнәкләренең яңарып торуы кирәк. Хәтере беткән кешене хәтерсез милләт белән дә чагыштырып буладыр. Дөньяга, яшәешкә гамь бетә икән, бу инде тормыш тукталды дигән сүз. Ящик әле, без – дөньядан, дөнья бездән туймаган. Конгресс исә күпмедер дәрәҗәдә милләтнең баш мие функциясен дә башкарырга тиештер. Һәрхәлдә, шулай уйлыйбыз.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ:

«БЕЗ ҮЗ КИЛӘЧӘГЕБЕЗНЕ КҮРӘБЕЗ»

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫНЫҢ «ТАТАРЛАР: ТРАДИЦИЯЛӘРГӘ ТУГРЫЛЫК, КИЛӘЧӘККӘ ЫШАНЫЧ» МӘКАЛӘСЕННӘН

Вазгыять һәм гамәл

Соңгы вакытта «дошман»ны күбрәк читтән эзләү гадәткә керде – глобальләшү, интернет, массакүләм культура, хокукый чикләүләр һәм башкалар. Сүз дә юк, тирә-юньдә хәвеф-хәтәр җитәрлек. Ә үз күңелеңдә ничек сакларга милли хисләрне? Бу көн саен кылынырга тиешле эчке батырлыкка әйләнеп бара түгелме? Кылыргамы-юкмы – һәркем үзе хәл итә.

Тарихтан шулай килеп чыккан: татарларның берләшүе өчен җаваплылык хәзерге Татарстанга йөкләнгән. Кайда яшәвебезгә карамастан, һәрберебез өчен аның кайгыртуын тоеп яшәү гаять мөһим. Шуңа күрә Бөтендөнья татар конгрессы эшчәнлегенә ярдәм күрсәтелә, ана телен, мәдәниятне, милли тәңгәллекне саклау программалары төзелә, грантлар гамәлгә куела – болар хәзерге көн бурычларын хәл итүнең сизгер ысуллары. Бу эшне без һичшиксез дәвам итәчәкбез.

Татар халкының һәм Татарстанның аерым юлы турында сөйләгәндә, кайбер кайнар башлар моны аерылып чыгу сәясәте дип күрсәтергә маташа. Кемнәрдер, үзләренә сәяси дәрәҗә өстәргә тырышып, Татарстаннан уен картасы ясамакчы, илнең үзәгендә тарткалашу утравы дигән уйдырма таратмакчы булалар. Россиядә татарлар – саннары буенча икенче урында торучы халык, шуңа да карамастан, хәтта үз илебездә безнең тарихыбызны һәм мәдәниятебезне белеп бетермиләр. Еш кына аңлатып бирергә туры килә: гаять катлаулы үзгәртеп кору елларында Татарстан үзенең хокукларын һәм вәкаләтләрен үз социаль-икътисади мөмкинлекләренә, илнең үсешенә керткән өлешенә тәңгәл рәвештә киңәйтүгә омтылды, бары шул гына. Киресенчә, безнең республика, үз эчендә милләтара һәм динара татулыкны саклап калып, Россия дәүләтчелеген ныгытуга зур өлеш кертте.

> „Татарлар – һәр заманда иҗтиһадка, җәмгыятьне берләштерүгә хезмәт итүче халык. Менә ни өчен безнең мәдәният, ватанпәрвәрлек һәм дөньяны күзаллау үзенчәлекләре, татарлар өчен туган телнең зур әһәмияткә ия булуы турында сөйләү бик мөһим. Боларга татарларның мәгънә коды салынган, ул милләтебезнең дөньяга карашын һәм әхлакый хәзинәләрен тирәнрәк аңлау мөмкинлеге бирә.

Без сабыйлар түгел, безгә кулыбыздан җитәкләп, карап-кайгыртып йөртүчеләр кирәкми. Кулыбызга бәхеткә ирешүнең әзер әмәлен китереп тоттыруны да көтеп утырмыйбыз. Телебезне, традицияләребезне саклау өчен дә, халкыбыз өчен кадерле нәрсәләрне киләсе буыннарга тапшыру өчен дә җаваплылыкны үз өстебезгә алырга әзер без. Нинди генә катлаулы тарихи вакыйгалар булса да, без бирешмәдек, нык тордык. Алга таба да шулай булачак.

tatarstan.ru

Алга таба юлыбызны без нидә күрәбез? Без аны мәгърифәттә күрәбез. Татарлар һәрвакыт белем алуга, гыйлемле булуга омтылды, яшәешкә фәнни караш белән аерылып торган. Зыялылар үз көчен халыкның аң-белемен арттыруга, мәдәниятне таратуга һәм алгарышка куйган. Без кайчак үзебезнең фән ягыннан көчлебезне һәм каршыбызда ачылып килүче яңа мөмкинлекләрне тиешенчә бәяләп бетермибез. Фән-гыйлемнең өметле өлкәләрен һәм юнәлешләрен үстерергә, белем бирү ресурсларының зур мөмкинлекләреннән файдаланырга кирәк. Югары дәрәҗәдәге белем, һөнәрләр, күнекмәләр – хәзерге дөньяда конкурентлыкка сәләтле булуның нигезе.

Без киләчәгебезне балаларга традицияләребезне тапшыруда күрәбез. Хәдисләрнең берсендә: «Бер генә ата да үзенең баласына яхшы тәрбиядән дә кыйммәтлерәк нәрсә бирә алмый», – дигән фикер әйтелә. Мин моның, динемә һәм милләтемә карамастан, һәр кеше өчен әһәмияткә ия әхлакый күрсәтмә булуына ышанам. Балаларыбыз язмышы өчен без җаваплы. Аларны халкыбызның һәм Ватаныбызның лаеклы уллары һәм кызлары итеп тәрбияләү – безнең бурыч.

Укытучыга карата олы ихтирам татарларга гомер-гомергә хас. Хәзерге көндә татар телен һәм мәдәниятен үз җилкәләрендә алып баручы тәрбиячеләргә һәм укытучыларга рәхмәт сүзләребезне җиткерәбез. Без укытучыларга, аларның иҗади хезмәтенә ярдәм итәбез һәм итәчәкбез, чөнки иҗади башлангычтан һәм илһамлы халәттән башка алар үзләренең мөһим вазыйфаларын үти алмыйлар. Балалар өчен, балалар катнаша торган иҗади проектлар идеяләренең барлыкка килүенә дә, аларны гамәлләштерүгә дә булышачакбыз. Чөнки газиз тел-сүзебезне, газиз җыр-моңнарыбызны саклау – рәсми күрсәтмә дә, һөнәри вазыйфа яки дәрес бирү дә түгел, ул – үз халкыңа мәхәббәт, ата-бабаларга ихтирам һәм әхлакый бурыч.

Ахыры 2 нче биттә >

> *Мин – татар! Син – татар! Без – татар!*
> *Ашыкма сызарга исәптән.*
> *Нәкъ вакыт – иярә менәргә*
> *Кодрәтне уятып йөрәктән!*
>
> Гөлүсә БАТТАЛОВА

Хуш киләсез!

Роберт НИГЪМӘТУЛЛИН, Россия галим-механигы, П.П. Ширшов исемендәге океанология институтының фәнни җитәкчесе (Мәскәү):
– Съезд – минем өчен халыкның берләшүе, тәҗрибә уртаклашуы, милли дөньядагы мөһим вакыйга. Аеруча татар теленә, татар мәктәпләре темасына зур игътибар күрсәтер идем. Мин берничә тапкыр милли мәктәпләр өчен ике телле (русча-татарча, русча-башкортча, русча-чуашча) БДИ бирү тәкъдимен күтәреп чыктым. Ләкин бу, кызганыч, тормышка ашырылмады. Бу яктан конгрессның эшлисе эшләре күп әле.

Фәнир ГАЛИМОВ, «Россиянең татар авыллары» советы рәисе (Башкортстан):
– Мондый катлаулы чорда һәр куелган максатны үтәп чыгу җиңел эш түгел. Мәсәлән, Башкортстандагы хәлләрне тиешле югарылыкка күтәреп, үзебезнең татарлыгыбызны күрсәтеп-әйтеп бетерел булмады. Халык санын алу барышында эшләнеп бетмәгән эшләр калды. Билгеле, аның үз сәбәпләре бар. Киләчәктә шушы мәсьәләне конгресс белән берләктә ахырга җиткерә алсак иде. Үзебезне үзебез яклардык, телебезне, гореф-гадәтләрне саклап кала алырлык булсак иде. Әлегә иң борчыганы шушы. Калган башка бурычларны конгресс 150 процентка үтәде. Кем белән генә сөйләшсәм дә, канәгатьлек зур. Аеруча гореф-гадәтләрне барлау, туплау, күрсәтү буенча зур эш алып барылды. Бәйрәмнәр оештыру да халыкны берләштерә. Анда без бер-беребезне күрә, үз сүзебезне әйтә алабыз. Тарихчылар да актив эшли. Алар шулкадәр эчкерсез, бөтен җаннарын-тәннәрен биреп эшлиләр. Мин аларга мең рәхмәтле. Авыл эшмәкәрләрен җыю да – зур чара. Соңгы елларда яшьләр дә тартыла. Бу – аеруча сөенечле күренеш. Киләчәктә аларны тагын да күбрәк җәлеп итәргә кирәк.

Рәмзия ГАББАСОВА, Удмуртиянең «Яңарыш» газетасы баш мөхәррире, Удмуртия татарларының милли-мәдәни автономиясе рәисе:
– 30 ел элек Бөтендөнья татар конгрессының оешуы безнең өчен зур бәхет булды. Чөнки ул булмаса, без бүгенгебез, милли тормыштагы уңышларыбыз белән мактана алмас идек. 1990 нчы елларда төбәкләрдә милли оешмалар барлыкка килде. Бөтендөнья татар конгрессының аларны үз канаты астына алуы һәм юл күрсәтүе бик кирәкле эш иде. Ул төбәкләрдәге оешмалар өчен маяк булды. Мин үзебезнең элеккеге оешма җитәкчесе Мәсгуть ага Гаратуев белән чын күңелдән горурланам. Нәкъ менә ул милли оешманы барлыкка китерүгә һәм Удмуртиядә Милли сәясәт министрлыгы оешуга да бик зур өлеш кертте. Шулай ук Бөтендөнья татар конгрессының I һәм II съездларында, аны оештыру эшләрендә дә катнашты. Димәк, бу эшләрдә Удмуртиянең дә өлеше бар, дип горурланып әйтә алабыз.

Бүген без Бөтендөнья татар конгрессы белән кулга кул тотынышып эшлибез. Нинди генә чаралар уздырсак та, аңа мөрәҗәгать итәбез. Бер генә проектыбыз да алардан башка тормышка ашмый. Бигрәк тә соңгы 5 елда конгресснның ярдәмен аеруча нык тоябыз.

Соңгы ун елда Татарстан Хөкүмәте ярдәмендә читтә яшәүче татарлар өчен конкурслар оештырып, проектларга акча бирәләр. Бу – безнең өчен күктән төшкән бәхет. Чөнки элек милли оешмалар оешкан вакытта нинди генә эшкә алынсак та, акча эзләп йөрергә туры килә иде. Хәзер проектларны тормышка ашыру нәтиҗәсендә бөтен ансамбльләребез диярлек костюмлы булдылар, уен коралары белән баедылар, китаплар чыгардык, фильмнар төшердек. Болар барысы да – уртак көч белән башкарылган эш нәтиҗәсе.

Милли стратегия һәркайсыбызның өстәл китабына әйләнде, ул эшләребезгә юнәлеш биреп тора. Шуңа күрә конгресска без зур рәхмәтлебез белдерәп, уңышлар телибез. Татарстан Хөкүмәте алга таба да безне ярдәменнән ташламас, барлык конкурслар да дәвам итәр дип ышанам, чөнки бу конкурсларсыз безнең башка милли тормышыбызны күз алдына да китереп булмый.

Илдар МӘҮЛӘТОВ, Пенза өлкәсенең мәдәният һәм туризм министры урынбасары:
– Мин быел съездда беренче тапкыр гына катнашам. Шуңа күрә барысы да яңа булачак. Шәхсән үзем төбәкләр арасында узара хезмәттәшлек көтәм. Бигрәк тә үзебезнең юнәлеш буенча яңалык алырга өметләнәм. Пенза өлкәсе белән Татарстанның туризм буенча элемтәләре ныклы, уртак проектлар барлыкка килсен иде дип телим.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Имла язмышында – милләт язмышлары

Иртәгә – 31 июльдә Татар язуы көне билгеләп үтелә. Кайберәүләр аны Татар әлифбасы көне дип тә атый. Галимнәр әйтүенчә, безнең борынгы бабаларыбыз сүзләрне һәм авазларны символлар (тамгалар) белән моннан 1470 ел элек – 552 нче еллар тирәсендә билгели башлый. Ул эш Урта гасырларның иң зур дәүләтләренең берсе – Кырымнан Монголиягә тикле сузылган Төрки каһанлыкта гадәткә керә. Дәүләтнең яралу вакытының да шул датага барып тоташуы мәгълүм. Тарихчылар, каһанлык төзелгәч, билгеләр кулланып мәгълүмат алышуның шактый киң төсмер алуын – аның хәтта ки дәүләт эшләрендә кулланыла башлавын әйтә. Шунысы да билгеле: ул тамгалар, ул язу алымы озак еллар дәвамында кайбер башка халыклар да кулланган рун язуы рәвешендә башкарыла.

Халыкларның, шул исәптән төрки бабаларыбызның да язуга тартылуын – сүз, иҗек, авазларны билгеләр аша белдерә башлавын, беренче чорларда ул гамәл камиллектән ерак торган мәлдә дә, бөек алгарыш, дип бәяләү дөрестер. Тел ялау – кеше затларының сүзләр кулланып, бер-берсенә теләк, карашларын җиткерергә өйрәнүе кыргыйлыктан цивилизация юлына чыгуда беренче адым булса, язу туу – икенче зур адым. Телдән-телгә тарихи вакыйгаларны, халык авыз иҗатын, аерым кешеләрнең затлы фикерләрен бары берничә буынга гына ирештереп була. Ә инде хәрефләр кулланып, «ташка басылган» мәгълүмат гасырлардан гасырларга күчә, тарихта кала. Һәм бу бик мөһим. Төрле язу рәвешләре, имла, әлифбалар тумаган, ялмаган булса, кешелек үзенең үткәнен ифрат та начар белер яисә бөтенләй дә белмәс иде. Галимнәр генә түгел, гади халык та тарихны тиешле дәрәҗәдә үзләштергән, үткәннән сабак алып яшәү гадәткә әйләнгән очракта, без – адәми затлар, ихтимал, кешене кеше итүче өченче адымга да дәгъва кыла башларбыз…

Рун язуына кайтканда, андый язу килеп чыгышының Төньяк Европага – бүгенге Дания, Швеция, Норвегия территориясендә яшәгән халыкларга барып тоташуы мәгълүм. Шуны белгән хәлдә, төрки кавемнәргә ул язу рәвеше шул тарафлардан кергән дияргә дә күпмедер нигез бар кебек. Ләкин белгечләр арасында беренче төрки «әлифба» нәсел, токым тамгаларыннан, төрле пиктограммалардан ялган, читтән кермәгән, диючеләрнең өстенлек итүе дә мәгълүм. Ни генә булмасын, 922 елга яки Идел буе Болгар дәүләте ислам динен кабул иткәнчегә чаклы, бабаларыбыз үзләренең уй-фикерләрен ташка, агачка, сөяккә чокып, рун язуында язган. Ислам кабул ителүгә, халкыбыз руннан уңайлырак, камилрәк саналган гарәп әлифбасына күчә. Һәм мең ел буе шул имланы куллана.

Бүген һәммәбезгә мәгълүм: Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы, Сараи, Мөхәммәдьяр поэмаларыннан алып, XIX гасыр татар мәгърифәтчеләре, фикер ияләренең хезмәтләренә чаклы барысы да шул графикада башкарылып, алар бүген безгә бөек язма мирас кына түгел, олы мәдәни мирас булып та килеп ирешә. Элекке заманнарда, әлбәттә инде, китап басу булмаган. Шул ук әдәби әсәрләр, мөһим текстлар күчереп язу ысулы белән күбәйтелгән. Ул четерекле, катлаулы, сабырлык сораган эшне, гадәттә, мәдрәсә шәкертләре башкарып килгән, диләр. Китапларны матур итеп, бизәп, каллиграфия ысулы кулланып күчереп язу да булган. Халкыбыз, аның шактый өлеше озак дәверләр буе шуларны укып яшәгән, китапка олы ихтирам белән караган. Уку сәбәпле, ул һәрдаим мәгърифәткә, гыйлемгә тартылган. Табигый ки, андый традиция татарның телен, динен, милли мәдәниятен саклауда ифрат та зур роль уйнап торган.

Белгечләр әйтүенчә, мәсәлән, XIII гасырда ук язылган «Кыйссаи Йосыф» китабы Октябрь инкыйлабына чаклы дәверләрдә һәр татар йортында диярлек булган, кадерләп тотылган гына түгел, даими укылган да. Зур мәдрәсәләр карамагындагы китапханәләр исә күп буын шәкертләренә мәгърифәт нуры чәчкән. Китапны күчереп язудан туктап, аны күбәйтү типография ысулы белән башкарыла башлагач, укуга, аң-белемгә игътибар тагын да арта. Кайбер чыганаклар искәртүенчә, 1801–1917 елларга караган вакыт аралыгында татар телендә җәмгысы 15 мең исемдәге китап чыгып, аларның гомуми тиражы 50 миллионнан артып киткән.

Тик гарәп графикасында башкарылган мең елдан арткан язма мирасыбыз дигәндә, шунысы аяныч: сугышлар, төрле бәла-каза, ут-күз аркасында аның хәтсез өлеше юкка чыккан. Монголлар һөҗүме чорында Бөек Болгардагы күп кулъязма китаплар, елъязмалар, китапханәләр яндырыла. Казан алынганнан соң мәшһүр Хан китапханәсендәге меңәрләгән кулъязма китапның юкка чыгарылуы мәгълүм. Хәтта совет чорына кергәч тә, диннән баш тарттык, дигән булып, гарәп графикасы белән язылган бик күп китаплар чүплеккә ташлана. Шулар гына җитмәгән, 1927 елда СССР дигән илдә төрки халыкларны, шул исәптән татарларны да латин графикасына – Яңалифкә күчерәләр. Гарәп шрифтындагы хәзинәгә игътибар кимүгә бу хәл дә үз өлешен кертә.

Ул чор татар зыялыларының бер өлеше милләтне гарәп шрифтыннан, аның белән бергә ун гасырлык мәдәни мирастан аеруга каршы була. Бер төркем интеллигенция вәкилләре Сталин исеменә хат яза, тик аларның фикере искә алынмый. Большевикларга унификация – илдәге бар булган төрки халыкларның бер имлада булуы, милләтләр арасындагы чикләрнең бетә башлавы кирәк була. Хәзер яхшы аңлыйбыз: латинга күчеп, гомерлеккә шул имлада калган тәкъдирдә без зур югалтулар кичермәс тә идек. Ул гынамы, милләтебез бүген төрки дөньяга гына түгел, гомумән цивилизацияле илләргә, компьютер технологияләренә якынрак та торган булыр иде. Телебездәге авызлар яңгырашы да хәрефләргә күбрәк, ныграк тәңгәл киләсе иде. Ләкин…

Ләкин латинга күчеп, нибары 12 ел узуга – 1939да, илдә шәхес культы урнашып, унификациянең яңа этабына керү аркасында, кабаттан дистәләгән милләтләрнең, шул исәптән татарның да фикерен сорап тормастан, рус әлифбасы – кириллица кертелә. Илдә инде ике ел барган зур террор аркасында, татар интеллигенциясе үз карашын белдерергә базмый. Ул гынамы, зыялыларыбызга 1927 елда язылган хат өчен дә җавап тотарга туры килә. Җыеп әйткәндә, кыска гына вакыт аралыгында ике әлифба алыштырып, өченчесенә күчү милләтебез, аның язма мирасы өчен генә түгел, тел, тарих, мәдәният дигәндә дә шактый зур тетрәнү булганын искәртү дөрестер. Дәүләтчелеге булмаган халыкларга үз язмышын үзе билгеләү ифрат та авыр шул.

tatarstan.ru

ӨМЕТЛЕ ЕГЕТЛӘР

Кыю, гадел һәм көчле булыгыз! Быел Казанның танк училищесын бөркеттәй 111 егет тәмамлады. Уку йортын алтын медаль белән тәмамлаган 8 лейтенантка дипломнарны Президент Рөстәм Миңнеханов тапшырды. Тантаналы чарада без дә булып кайттык.

Иң элек училищеда «Үзәк хәрби округның тарихы һәм сугышчан традицияләре» музее ачылышы булды. Андагы экспозицияләрдә Россия армиясенең Бөек Ватан сугышы чорыннан алып бүгенгә кадәр үсеш тарихы чагылыш тапкан.

Шуннан соң Жуков орденлы, Кызыл Байраклы Казан югары танк команда училищесының 89 нчы чыгарылыш егетләре, Ватанны сакларга әзерлекләрен раслап, кулларына диплом алды. Шуларның 12се уку йортын – кызыл дипломга, ә 8е алтын медальгә тәмамлады. Тиешле ялдан соң алар, төрле гаскәрләргә бүленеп, хәрби хезмәткә китәчәк. Оборона министры Сергей Шойгу приказыннан күренгәнчә, Көнбатыш хәрби округка – 36, Көньяк хәрби округка – 21, Үзәк хәрби округка 18 егет юл тотачак. Моннан тыш, танк училищесын тәмамлаган 2 егет – һава-десант гаскәрләрендә, бер егет – Төньяк флотта, тагын берсе – Россия Кораллы көчләре генераль штабының Баш идарәсендә һәм өчесе Коры җир гаскәрләрендә хезмәт итәчәк.

Безнең Кораллы көчләрнең киләчәге – сезнең кулда. Президент Рөстәм Миңнеханов тантаналы чарада шулай дип белдерде.

– Сезгә фидакарьлек һәм намус, бердәмлек һәм ватанпәрвәрлек традицияләрен дәвам итәргә кирәк булачак. Бүгенге офицерлар – Бөек Ватан сугышы геройларының варислары, оныклары һәм оныкчыклары – Ватан өчен фидакарьләрчә көрәшәләр. Алар Сүриядә террорчыларга каршы көрәш алып бара, Донбассны неонацистлардан яклый, халкыбызның тынычлыгы, иминлеге сагында тора. Махсус хәрби операция барышында әлеге уку йортын тәмамлаган егетләрнең батырлыклары белән чын күңелдән горурланабыз, – диде ул. – Училище җитәкчелеге, мөгаллимнәр уку процессын нәтиҗәле, кызыклы һәм иҗади итү өчен бөтен көчен куйган. Шуңа күрә бүген безнең офицерлар фундаменталь әзерлек, уникаль күнекмәләр һәм зур осталыкка ия. Сезнең Казан танк училищесының данлы традицияләрен ныгытуга лаеклы өлеш кертәчәгегезгә ышанам. Офицер погоннары сезгә гаять зур җаваплылык йөкли. Солдатларыгызны саклагыз!

Үзәк хәрби округ командующие вазыйфаларын вакытлыча башкаручы генерал-майор Рөстәм Миңнекаев сүзләренчә, Казанда тәрбияләнгән офицерлар гаделлек, батырлык кебек күркәм сыйфатлары белән һәрвакыт аерылып торды.

– Ватаныбыз хакына намуслы һәм фидакарь хезмәт күрсәтергә әзер булыгыз. Өлкән иптәшләрегез алдында сынатмагыз, училищеның данлы традицияләренә тап төшермәгез. Мондагы командирларыгызны, укытучыларыгызны, аларның теләкләрен, тормыш сабакларын онытмагыз! – диде ул.

Бүгенге катлаулы вазгыятьтә уку йортында алган белем һәм тәҗрибәләрне тиешле дәрәҗәдә файдаланырга кирәк булачак. Танк училищесы башлыгы, генерал-майор Кирилл Кулаков шулай диде.

– Үзегезне, солдатларыгызны саклагыз. Нинди дәрәҗәле уку йортын тәмамлаганыгызны беркайчан да онытмагыз! Хәрби бурычыгызны үтәгәндә монда алган бәһасез тәҗрибәгезне лаеклы дәрәҗәдә күрсәтегез! – диде генерал-майор.

Танк училищесын алтын медальгә тәмамлаган Шамил Хәсәншин исә үз чиратында барлык егетләр исеменнән Ватанга лаеклы хезмәт итәргә вәгъдә бирде. «Уку җиңел булды дип әйтә алмыйм. Ләкин зур хыялым, әти-әниемнең һәм тормыш иптәшемнең сүзләре минем рухымны ныгытып торды. Нәселебездә хәрбиләр булмаса да, тәрбиям, Ватанга мәхәббәт мине хәрби белем алырга этәрде. Хәрби – иң кызыклы һәм иң хөрмәтле һөнәр ул, миңа калса», – диде егет.

Ә газиз улларын котларга килгән әти-әниләр күз яшьләрен тыя алмады. «Улым өчен бик горурланабыз. Әлеге уку йорты безнең егетләрне чын батыр булырга, туган илне яратырга өйрәтте. Антларына тугры калып, лаеклы кешеләр булсыннар иде», – диде Эльмира ханым, улын кочакларга ашыгып.

Ә кем өчендер бу көн икеләтә шатлыклы булды. Вальс биегән вакытта ике егет сөйгән ярларына тормыш юлларын бергә бәйләргә тәкъдим ясады. Яшьләргә бәхет телибез!

Лилия ГЫЙМАЗОВА

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ:

«Без үз киләчәгебезне күрәбез»

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Без үз киләчәгебезне туган телне, мәдәниятебезне, милли рухи һәм әхлакый юнәлешебезне, динебезне саклауда күрәбез. Татарча әйбәт сөйләшәсеңме, дини йолаларны үтисеңме – болар ул кадәр үк әһәмиятле түгел. Татар булу – үз халкың белән тыгыз бәйләнеш тою дигән сүз. Әгәр дә син ата-бабаларың сөйләшкән телне өйрәнергә теләсәң, без ярдәм кулы сузарга һәрчак әзер. Без туган телне саклау өчен барысын да эшләячәкбез, бәлки киләчәктә синең дә бу эшкә катнашасың килер.

Чагыштырмача күптән түгел Зиннур Мансуровның даһи татар шагыйре иҗатына нигезләнгән «Тукайча татар кодексы» дигән хезмәте дөнья күрде. Анда бик дөрес әйтелә: уку – үз халкыңа хезмәт итү ул. Белем алу үз-үзеңне туктаусыз камилләштерүне, үстерүне, тырышып эшләүне таләп итә. Без ышанычлы киләчәгебезне чит фикерләргә таянмыйча, үзебезнең тирән белемебезгә һәм тупланган тәҗрибәбезгә нигезләнеп, үзебез төзергә сәләтле.

> Без үз киләчәгебезне үткәнебезгә ихтирамлы мөнәсәбәттә күрәбез. Безнең тарих – архив документлары һәм истәлекле даталар җыелмасы түгел, ул – күтәрелешләрдән һәм түбән төшүләрдән торган, лаеклы үтелгән олы юл, һәм ул халык хәтерендә сакланырга тиеш. Безнең тарих – бөтен дөнья һәм илебез фәненә, мәгарифенә, мәдәниятенә, сәнгатенә һәм башка иҗтимагый әһәмиятле өлкәләренә өлеш керткән һәм кертәчәк күренекле шәхесләр ул.

Без үз киләчәгебезне халкыбызның иҗади башлангычларын үстерүдә күрәбез. Йөрәктән агылучы татар моңы, сәнгатьнең төрле төрләрендәге традицион татар үзенчәлекләре модага һәм заманга бәйле түгел. Халыкның мәдәнияте аның белән бергә яши, үсә һәм үзгәрә. Ул – аның көзгесе.

Без үз киләчәгебезне халкыбызның мәдәни мирасын саклауда һәм баетуда күрәбез. Татарлар – күпмилләтле Россиянең һәм күпмилләтле дөньяның бер өлеше. Халыклар бер-берсеннән көчле үзенчәлекләре белән аерылып торуга карамастан, әхлакый нигезләр һәм рухи хәзинәләр уртак: Ватанга мәхәббәт, якыннарыңны, туганнарыңны ярату, ярдәмчеллек, игелек, миһербанлык, намуслылык, ихласлык, үзеңне һәм башкаларны хөрмәт итү. Һәм бу идеяләр җанга якын газиз мәдәниятебез, милли образлар һәм үрнәкләр аша табигый рәвештә күңелгә сеңә, дөнья мирасын баета.

Без үз киләчәгебезне энтузиастларда – иҗтимагый оешмаларда һәм татар халкының актив улларында һәм кызларында күрәбез. Теләсә нинди, хәтта бик кечкенә генә ярдәм дә – зур бурычларны хәл итүгә өлеш кертү ул.

Без үз киләчәгебезне күрәбез. Без – тарихи әһәмияткә ия бербөтен халык, без үзенчәлекле, безнең үз орбитабыз бар, әмма ул күпмилләтле уртак йолдызлыкта урнашкан.

> Без үз киләчәгебезне нәрсәдә күрмибез? «Сувенир халык» булуда. Шуны онытмаска кирәк: милләт тиз генә юкка чыга алмый, ә юкка чыкса, аны беркайчан да кайтарып булмаячак.

Без ата-бабаларыбызның бөек казанышлары рухына төрелгән газиз җиребездә дөньяга килү, яшәү һәм үз халкыбызга файда китерү бәхетенә ия. Татарстан бүген – киләчәккә омтылучы республика, бездә яшәү һәм эшләү өметле һәм уңайлы. Татарстан – безнең горурлыгыбыз һәм иртәгәге көнгә ышанычыбыз. Без, татарлар, кайда гына гомер итсәк тә, һәрвакыт ата-бабаларыбыздан килгән рухи бердәмлек көчен, халкыбыз көчен тоеп яшибез.

Без киләчәктә дә үз тарихыбызны үзебез язарга, үз киләчәгебезне үзебез төзергә телибез! Киләчәгебез якты һәм бик күп, бик күп буыннар өчен уңышлы булсын иде!

2020 ел

ТУЛЫ ВАРИАНТЫ – VATANTAT.RU САЙТЫНДА

ХӘЛ ТОТРЫКЛЫ. ӘЛЕГӘ

Яшәеш

Битлексез булмас. Әгәр республикада коронавирус очраклары артып китсә, яңадан битлекләребезне алып киячәкбез. Белгечләр кисәтә: көз айларында болай да тын юлы авырулары, салкын тиюләр арта, шуңа өстәп коронавирус та таралырга мөмкин. Шөкер, әлегә Татарстанда коронавирусның «кентавр» төре теркәлмәгән. Ә менә «омикрон»ның төрле формалары белән авыручылар бар икән. Татарстанда узган тәүлектә 47 кешедә коронавирус инфекциясе ачыкланган, 7,5 мең тест үткәрелгән. Чир чыкканнан бирле 153754 кеше авырган. «Омикрон»ның исә барлыгы 1309 очрагы теркәлгән. 34 кеше авыруны – чит илдә, 1275е республикада йоктырган.

«Татар-информ» агентлыгында узган матбугат конференциясендә Кулланучы хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең (Роспотребнадзор) Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина, республикада әлегә хәлләр тотрыклы, диде.

– Без ялдан кайтучыларны аэропортта тикшерәбез. Шушы көннәрдә 46 очкыч тикшерелде. Шуның 12се чит илдән кайтучылар иде. Алар арасында тән температурасы күтәрелгән яки авырган кешеләр ачыкланмады, – ди ул.

Любовь Авдонина, чит илгә барып ял итеп кайтучылар барлык тиешле таләпләрне үтәми, дип тә зарлана. Кайткач бирергә тиешле анализлар турында онытарлар. Баксаң, күп очракта таләпләрне үтәмәүчеләрне штрафка тартырга туры килә икән. Күзәтү дигәннән, җәйге балалар лагерьлары да белгечләр контролендә. Республикада 111 лагерь эшли. Анда 18560 бала ял итә икән. 15 палаткалы лагерьда ял итүче 2 мең бала да бар.

– Балаларның сәламәтлеге һәрдаим күзәтү астында. Ротавирус очраклары да теркәлеп тора. Гөмбә ашап, нитратлы яшелчә, җиләк-җимеш белән агуланучылар да бар, – ди Любовь Авдонина.

Ә менә өлкәннәр үзләрен-үзләре контрольдә тотарга тиеш. Вакытында ясатылган прививка авырудан саклый, ди Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш эпидемиологы, иммунопрофилактика буенча белгече Дмитрий Лопушов.

– Бүген республикада 18 йогышлы авырулар госпитале эшли. Аларда 450 кешелек урын бар. Әлегә ятакларның 8 проценты буш. Коронавирустан 48 бала хастаханәдә дәвалана, 227се өй шартларында сәламәтлеген ныгыта. Авырган балаларның барысы да вакцинасыз. Прививка ясатам дигән кешегә республикада «Спутник» вакцинасы җитәрлек. Шуңа күрә әгәр сезнең яңадан прививка ясатыр вакытыгыз җиткән икән яки авырганнан соң 6 ай узса, әлбәттә, алдан хәстәрен күреп куярга кирәк. Авыргач инде соң була, – ди табиб.

Очрашуда битлек кию-кимәү турында да сорадылар. Дмитрий Лопушов сүзләренчә, медицина оешмаларына барганда һәркем битлек киярга тиеш. Ул анда төрле вируслар йөргәнен, табибка килүчеләрнең 80 проценты авыру икәнен искәртте.

– Хастаханәләрдә битлек кию дигән таләп юк. Әмма мин аны кияргә киңәш итәр идем. Табиблар аны салып та тормады диярлек. Авыруның нинди чир белән килгәнен анализлар әзер булмыйча берәү дә белми бит, – ди ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА


Илдар Мөхәммәтҗанов

«МИЛЛӘТЕБЕЗ ҮЗ ЙӨЗЕНӘ ТАП ТӨШЕРМӘДЕ»

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ПРЕЗИДЕНТЫ МИНТИМЕР ШӘРИП УЛЫ ШӘЙМИЕВНЕҢ БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ СЪЕЗДЫНДА ЯСАГАН ЧЫГЫШЫННАН

Юл башы

Кадерле кунаклар, ватандашлар – татар халкының газиз уллары һәм кызлары!

Без бирегә, үзебезнең тарихи Ватаныбызга, үз дәүләтебез Татарстанга төрле иллэрдән җыелдык. Без – бүген Җир шарында көн күрүче татарларны берләштерүче, барлык татарлар исеменнән рәсми сүз әйтә алучы олы һәм вәкаләтле мәҗлес. Ата-бабаларыбыздан калган, тарихның иң кырыс җилләрендә дә тузмаган-таушалмаган гадәт буенча сезгә: «Исән-имин килеп җиттегезме? Өстәлләребез түгәрәк, мәҗлесебез мөбарәк булсын!» – дип әйтергә рөхсәт итегез.

Ә тарих җиле, язмыш җиле татарларны континентлар, илләр буйлап сипкән дә сипкән: ата-аналар – улларыннан-кызларыннан, туганнар – бер-берсеннән, дуслар дусларыннан аерылган. Без бүгенгә кадәр:

«*Сибелә чәчәк җилләр искәндә,*
Өзелә үзәк исемә төшкәндә», –

дип бер-беребезне сагынышып, сулыгып-сулыгып җырлыйбыз.

Бүген Казаныбызга – бөтен татар халкының төп йорты булган Татарстан башкаласына – Башкортстанда, Үзбәкстан, Казахстан, Төмән өлкәсе, Урал, Идел буе, Мәскәү һәм Санкт-Петербургта, Себердә, күрше республикаларда һәм өлкәләрдә, Бердәмлек дәүләтләрендә яшәүче ватандашларыбыз килде. Татарлар көн итмәгән республиканы яки өлкәне табу кыен һәм алар барысы да дәүләтебезнең башкаласы Казанга үзләренең вәкилләрен җибәрделәр.

Чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез хакында аерым әйтергә телим. Озак еллар буе без алар белән әйбәтләп аралаша алмадык. Монда безнең гаеп юк. Тарих, ачы язмыш шулайрак булды. Татарлар Татарстанга килеп, мәдәни, фәнни һәм экономик элемтәләр урнаштырдылар, Сабантуйларда булдылар, үзләренең туган-тумачаларын, ата-бабаларының каберләрен эзләп таптылар, яңа дуслар булдырдылар. Ә безнең гражданнар туганнары, дуслары, коллегалары янына башка илләргә бардылар. Без моңа чын күңелдән шатланабыз, һәм, ниһаять, безгә АКШтан, Төркия, Финляндия, Германия, Польша, Япония, Австралия, Кытай, Швеция, Норвегия, Румыниядән абруйлы делегацияләр килгән күркәм көн дә менә җитте. Татарстан Республикасы аларның барысына да: «Уртак Ватаныбызга рәхим итегез, кардәшләр, милләттәшләр!» – дия ала. Кайда гына яшәсәләр дә, татарлар Татарстанның чын патриотлары булдылар, һәм моның өчен мин аларның барысына да, сезнең барыгызга да халкыбыз исеменнән олы рәхмәтемне белдерәм!

Минем Указ нигезендә чакырылган бу конгресс татарлар яши торган төбәкләрдә халыклар арасындагы дуслыкны тагын да ныгытуга юнәлдерелгән фактор булып хезмәт итәр дип өметләнәм һәм моңа иманым камил. Безнең ниятләребез ак, алар беркемнең мәнфәгатенә дә аяк чалмый һәм без бу хакта бүген дөнья каршында ачыктан-ачык әйтәбез.

Халкыбыз өлешенә михнәтле язмыш туры килде. Анда горурланып сөйләрлек сәхифәләр булган кебек, үтә авыр түбәнсетү еллары да булды… Бүген узганнарны искә төшереп яраларга тоз саласы да килми, ләкин дәреслекләрдә, фәнни һәм матур әдәбиятта тарихыбызның гаять дәрәҗәдә бозып күрсәтелүе йөрәкләребезне әрнетә. Татарлар турында ялган-уйдырмалар бихисап күп җыелды шул. Кайбер халыкларда татар сүзе үзе үк курку һәм ышанмаучылык тудырды. Татар халкы мондый гаделсезлеккә лаек түгел. Ул гомер-гомергә тыныч хезмәт белән шөгыльләнде, икмәк үстерде, сәүдә итте, китаплар бастырып таратты, татар балаларына гына түгел, Шәрекъ халыкларының күпчелек ул-кызларына мәгърифәт нуры чәчте, укытты, сугышырга туры килгәндә дә, фәкать үзенең газиз җирен генә яклады. Без дөнья җәмәгатьчелеге аңында «явыз» татарлар, татар-монгол изүе хакында уйдырмаларны юк итәргә, безнең халкыбызга һәм республикабызга карата ялган карашларны бетерергә тиешбез. Бу – безнең бурыч.

> Татарлар турында нәрсә генә сөйләсәләр дә, милләтебез бернинди гамәле белән дә үз йөзенә тап төшермәде. Безнең оялыр урыныбыз юк. Халыкның иң күркәм сыйфатлары буыннан-буынга күчеп барды, алар камилләштеләр, кайберләре вакытлар узу белән төшеп калдылар, ә кайберләре алдагы буыннарга тапшырылды.

Менә шул сыйфатларның берсенә – аң-белемгә омтылышка – аерым тукталасым килә. Күп кенә галимнәр татарларның бу асыл сыйфатын гаҗәпсенеп, басым ясап күрсәтәләр. Татарларның көнкүрешен һәм холык-фигылен озак еллар өйрәнгән Казан университеты профессоры Карл Фукс сокланып: «Читтән килгән һәр кешегә, гомумән алганда, Казан татарларының башкалар белән, хәтта Европа халыклары белән чагыштырганда да, белемлерәк булуы, һичшиксез, сәер тоелырга мөмкин. Укый һәм яза белмәгән татарны якташлары кешегә санамыйлар һәм ул, гражданин буларак, башкалар арасында абруйсыз», – дип язып калдыра. Хәзерге шартларда мондый сыйфат гаять мөһим, чөнки, ахыр чиктә, нәкъ менә белемле булу безне дөньяның алдынгы милләтләре рәтенә бастырырга мөмкин.

(…) 1990 елның 30 августында дәүләт суверенитеты турында Декларация игълан ителде. Ул Татарстанны суверен дәүләт итеп билгеләде, үз территориясендә Республика законнарының өстенлеген таныды, җирне, җир асты байлыкларын, табигать хәзинәләрен һәм башка ресурсларны республиканың күпмилләтле халкы мөлкәте итеп беркетте. Сәяси-хокукый планда бу – хокукый дәүләт нормаларына туры килә торган эш. Ул татар һәм рус халкының да, Татарстанда яшәүче башка милләтләрнең дә мәнфәгатьләренә җавап бирә. Декларация республикада милләтара мөнәсәбәтләрне ныгытуга хезмәт итә һәм мин аның бөтен татар милләтенең демократик омтылышларына туры килүенә чын күңелдән ышанам. Шуңа күрә дә бу көн бездә, хаклы рәвештә, Республика көне, олы бәйрәм көне итеп билгеләнде.

1992 елның 21 мартында уздырылган референдум Татарстанны Россия Федерациясе һәм башка республикалар, дәүләтләр белән үзенең мөнәсәбәтләрен тигез хокуклы килешүләр нигезендә билгеләүче суверен дәүләт дип игълан итүче сәяси курсны раслады. Шик-шөбһәләр алып ташланды. Без үз юлыбызны сайладык.

(…) Татарстанда безнең республиканы әүвәлгечә Россия составындагы гап-гади бер автономия сыйфатында сакларга тырышучылар да, Россия Федерациясе белән элемтәләрне тулысынча өзәргә чакыручы сәяси көчләр дә бар әле. Карашларның тегесе дә, бусы да кабул ителерлек түгел. Без сәясәтебезнең һәм экономикабызның нигезен тәшкил итүче үз суверенлыгыбызны корбан итә дә һәм шул ук вакытта Россия белән озак еллар яшәп килгән экономик һәм мәдәни элемтәләрне өзә дә алмыйбыз. Без үзара мөнәсәбәтләрдә иң кулай һәм җайлы юлларны табарга тиешбез. Экономикабыз да, геополитик хәлебез дә, Россиядә миллионлаган милләттәшләребезнең яшәве дә моны эшебездә исәпкә алырга мәҗбүр итә. Без тулаем татар халкы турында уйларга бурычлы. Мин Татарстан бөтен татар диаспорасын берләштерүче булырга һәм Россиянең милли сәясәтенә җитәрлек дәрәҗәдә йогынты ясарга тиеш дип исәплим.

(…) Теләсә кайсы милләт турында чыгарылган нефть тонналары, үстерелгән ашлык яки башка продукциягә карап кына түгел, ә аның мәдәниятенә, фән һәм техника өлкәсендәге казанышларына, атаклы шәхесләренә, язучыларына, шагыйрьләренә, галимнәренә карап фикер йөртәләр. Бу җәһәттән, мин әйтер идем, без – бәхетле милләт.

(…) Безнең мәдәниятебез, чыннан да, бик бай. Тик аның хакында, күренекле шәхесләребез хакында, башка халыклар димим инде, татарлар үзләре дә аз беләләр. Аларның һәркайсын искә төшерү һәм барысына да тиешле рәхмәтне әйтер вакыт җитте. Бүген кайсы сәяси эшлекле реакционер, ә кайсысы революционер, кайсы язучыны бастырырга һәм дәреслекләргә кертергә, ә кайсысын онытырга дип баш ватарга кирәкми. Аларның һәммәсе дә тормышыбызда үзенең урынын алды. Алар барысы да – озак көткән азатлык көнен якынайтырга омтылган кешеләр. Алар тормыш юлын лаеклы уздылар.

(…) Төрле республикаларда һәм өлкәләрдә яшәүче язучылар бер-берсе белән аралаша алмадылар. Без үзебезнең Үзбәкстанда, Казахстанда, Петербургта һәм башка төбәкләрдә иҗат итүче рәссамнарыбызны фәкать ишетеп кенә белә идек. Күп кенә татар архитекторлары бөтен ил буйлап шәһәрләр төзеделәр, кинематографистлар барлык республикаларда фильмнар төшерделәр, ләкин үзләренең белемнәрен һәм хезмәтләрен Татарстанга бирүдән мәхрүм иделәр. Хәзерге көннән башлап татар язучылары, композиторлары, рәссамнары, архитекторлары, кинематографистлары үзләрен, кайда гына яшәсәләр дә, безнең иҗат берлекләренең дә уртак гаиләсендә дип хис итсеннәр иде.

(…) XIX йөз ахыры – XX йөз башы татарлар өчен мәдәниятнең бик тиз үскән чоры булды. XXI гасыр чигендә торганда да татар милләтенең һәм аның мәдәниятенең үсешендә яңа күтәрелеш булыр дип ышанасы килә. Минем тарихи гаделлекнең тантана итүенә иманым камил.

19 июнь, 1992 ел

ТУЛЫ ВАРИАНТЫ – VATANTAT.RU САЙТЫНДА

БЕР МӘЙДАНДА

«Татар-информ»

1992 елның июнендә Татарстан Республикасы Президенты карары нигезендә Бөтендөнья татар конгрессы оеша һәм аның беренче съезды уза. Өч дистә елдан соң конгрессның татар дөньясында тоткан урыны, максатлары үзгәргәнме? Бу турыда Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Гаяз улы ШӘЙХРАЗЫЕВ белән сөйләшәбез.

:: Васил Гаязович, Бөтендөнья татар конгрессы эшчәнлегенең төп максаты нидән гыйбарәт?

– Бөтендөнья татар конгрессы – татар иҗтимагый берләшмәләре берлеге – Россия Федерациясе төбәкләрендә һәм чит илләрдә төзелгән 450дән артык милли-мәдәни оешманы берләштерә. Безнең максат – халкыбызны берләштерү, тарихыбыз, телебез, динебез, мәдәниятебез, әдәбиятыбыз, милли мирасыбызны саклау һәм баету. Менә 30 ел дәвамында Бөтендөнья татар конгрессы шушы юнәлештән тайпылмыйча эш итә. Дөньяга сибелгән халкыбызны бер мәйданга туплау, алар белән эзлекле эш алып баруыбыз ил күләмендә дә игътибар үзгендә. Россиянең тышкы эшләр министры Сергей Лавров Бөтендөнья татар конгрессының чит илләрдәге Россия ватандашларын алга этәрү һәм аларның мәнфәгатьләрен яклау эшенә зур өлеш кертүен ассызыклады. «Бөтендөнья татар конгрессы чит илләрдә Россия Федерациясенең барлык халыкларының мәнфәгатьләрен алга этәрү буенча «йомшак көч»нең мөһим инструментларыннан берсе булып тора. Казан чит илләрдә ватандашлар эшләре буенча хөкүмәт комиссиясенең бик актив катнашучысы буларак тәкъдим ителде, шулай ук Татарстаннан килгән дусларыбыз да Россия Федерациясе субъектлары башлыклары советында актив катнашалар, ул Россия Тышкы эшләр министрлыгы каршында эшли», – дип билгеләп үтте. Димәк, конгресс тарафыннан башкарылган эшләр эзсез үтми.

:: Бөтендөнья татар конгрессы нинди этапларны кичерде? Һәм хәзер ул нинди этапта?

– Гомумән алганда, татар җәмәгатьчелеге белән эшчәнлек Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев инициативасы һәм ярдәмендә яңа халыкара берләшмәне формалаштыруга бәйле. Беренче этап – Бөтендөнья татар конгрессы структураларын формалаштыру, программа һәм устав документларын эшләү һәм теркәү берлек эшчәнлегенең беренче биш – ун елына туры килә. Бу чорда илдә сәяси вазгыять, икътисад һәм финанслар катлаулы хәлдә иде. Нәкъ менә шул вакытта Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы хакимият органнары арасында вәкаләтләрне бүлешү турында килешү төзелде. Татарстанның федераль үзәк һәм төбәкләр белән хезмәттәшлеге мәсьәләсендә татар факторы роль уйнады.

Икенче этап – ил икътисадында һәм социаль үсешендә яңа цикл башлану, базар мөнәсәбәтләрен ныгыту. Ул Президентыбыз Рөстәм Миңнехановның Татарстан җитәкчелегендәге эшчәнлегенә бәйле. Президент татар җәмәгатьчелегенә һәрвакыт ярдәм итә, безнең проектларны тормышка ашыруга хәер-фатихасын бирә. Татарстан һәм татар дөньясы бер-берсенә таяна, ил һәм халык файдасына конструктив хезмәттәшлек итә. Бу чорда (2005–2010 еллардан башлап) төбәк татар үзәкләренең һәм иҗтимагый берләшмәләрнең, ассоциацияләрнең (яшьләр, хатын-кыз, эшмәкәрлек, дин әһелләренең) гамәли эшчәнлеге җайга салынды.

Хәзерге этап төбәкара элемтәләрне үстерүгә һәм татарлар яшәгән төбәкләрнең хакимият органнары белән хезмәттәшлекне үстерүгә багышланган. Бу чорда 1000 һәм аннан да күбрәк кеше катнашында зур масштаблы чаралар, форумнар, россиялеләрне патриотик рухта тәрбияләүгә юнәлдерелгән халыкара конкурслар үткәрелә. Эпидемияләр, кризислы төбәкләрдә катлаулы халыкара вакыйгалар татар дөньясы өчен дә сынау булып тора.

> Татарларның милли җәмгыятьләре илнең һәм дөньяның төрле төбәкләрендә урнашкан. Шуңа күрә Бөтендөнья татар конгрессы хәзерге катлаулы шартларда позитив булырга омтыла, чөнки без сәламәт, патриотик көчләр, конструктив һәм гуманлы бурычлар тирәсендә берләшергә тиешбез.

:: Өч дистә ел эчендә Бөтендөнья татар конгрессында иң төп казанышлар нинди булды?

– Әйткәнемчә, Бөтендөнья татар конгрессы безнең барлык милләттәшләребезне берләштерү үзәге һәм таянычы булып тора. Бу еллар эчендә без бөтен дөнья буйлап татарларның этномәдәни үзенчәлеген, милли үзенчәлеген саклау утрауларын булдыра алдык. Күпьеллык системалы эшчәнлекнең иң мөһим нәтиҗәләреннән берсе – «Татарлар: гамәл стратегиясе» документын булдыру һәм кабул итү. Аның нигезендә гамәлдәге стратегияне гамәлгә ашыру буенча эшчәнлекнең төп юнәлешләре эшләнде. Йөзләгән милли оешма һәм мәдәни үзәкләр гуманитар процессларга этномәдәни йогынты ясау коралы алды.

:: Моннан 5 ел элек барлыкка килгән Милли Шура нинди роль уйный? Бу структура үз эшчәнлеген акладымы икән?

– Милли Шура булдыру татар милли үсешенең магистраль юлларын билгели һәм координацияли. Алар нигезендә татар җәмгыятьләре һәм оешмалары гуманитар юнәлешләр буенча гамәли эш алып бара. Ә Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты, көчләрне мобилизацияләүне, кадрлар һәм оештыру мөмкинлекләрен һәм ресурсларын координацияләүне тәэмин итә.

:: Васил Гаязович, Милли Шура рәисе булып сайлангач узган 5 ел сезнең тормышны, яшәешне, дөньяга карашны үзгәрттеме?

– Бик нык үзгәртте дип әйтә алмыйм. Беренчедән, мин бу эшкә татар кешесе буларак та, җитәкче буларак та әзер идем. Икенчедән, Бөтендөнья татар конгрессына килгәч, хезмәткәрләр белән бер команда булып эшли башлагач, эшнең асылына төшенергә авыр булмады. Җай гына татар дөньясы агымына кереп киттем.

Милли Шура сайлангач, Бөтендөнья татар конгрессының эшчәнлеге хөкүмәт дәрәҗәсенә күтәрелде. Россиянең башка өлкәләрендә, республикаларында милләттәшләребезне борчыган мәсьәләләрнең шактые уңай хәл ителде. Татар шәхесләренә һәйкәлләр куелды, истәлек такталары ачылды, музейлар төзелде, татар оешмаларының офислары барлыкка килде, милли үзәкләр, парклар төзелде…

:: Шушы биш ел эчендә сезнең тарафтан кайсы төбәктә башкарылган эшне зуры, иң уңышлысы дип саныйсыз?

– Кайбер кешегә 1 сум бирәсең, ул сиңа гомер буе рәхмәт укый. Кемгәдер миллион бирсәң дә җитми яки ул аны оныта. Шуңа күрә минем үзем өчен дә һәм безнең команда өчен дә зур һәм кечкенә эшләр юк. Аннан, зур эшне ничек бәяләргә соң? Сумнар беләнме, квадрат метрлар беләнме? Һәр эш чын күңелдән башкарылырга, йөрәктән чыгарга һәм халкыбызга файдалы булырга тиеш.

Бөтендөнья татар конгрессының 30 еллык тарихында халкыбыз өчен шактый игелекле эшләр кылынган. Беренче җитәкчебез – тарих фәннәре докторы, академик Индус Таһиров 1992 елдан 2002 елга кадәр эшләп, татар оешмаларын берләштереп, бүгенге конгрессның нигезен һәм кирпечләрен сала. Аннан соң килгән җитәкче Ринат Закиров, шул фундаментка таянып, күп кенә проектларны тормышка ашырды. Мин килгәч, без шул проектларны дәвам итеп, баетып, регионнардагы милли оешма җитәкчеләребез һәм ул төбәкләрнең хакимиятләре белән берлектә эш алып бара башладык. Бу инде – татар эшләрен оештыру нигезенә хөкүмәт ягыннан турыдан-туры ярдәм алу. Һәр этапның үз вакыты, үз эше бар. Әйткәнемчә, мин тормышка ашырылган эшне азга да, күпкә дә бүлмим. Үткән көн, нинди генә булса да, бәхетле булырга тиеш. Татар кайда гына яшәсә дә, без, Казаннан килеп, аларга ярдәм итә, файда китерә алабыз икән, шушы ярдәмне файдаланып, халкыбызга уңайлык тудырабыз икән, безнең миссия үтәлгән дигән сүз.

Әңгәмәдәш – Гөлназ ШӘЙХИ

Татармын! Горурмын!

Илшат НУРИЕВ, Арча районы башлыгы:

– Татарлык һәркемнең күңелендә булырга тиеш ул. Мин еш кына шагыйрь Разил Вәлиевнең, телне саклау түгел, сөйләшү кирәк, дигән сүзләренә тукталам. Татар теле яшәсен дисәк, өйдә, туганнар белән гел үз телеңдә сөйләшергә кирәк. Мин кая барсам да, иң элек сүзне татарча башлыйм. Читтәге милләттәшләрне карагыз. Алар телне кадерләп саклый. Халкың белән сөйләшсәң генә телне үстереп була. Мин гел бер фикер әйтәм: мәктәптә бала башлангыч белемне татарча алырга тиеш. Олырак сыйныфларда физика, химия, биология керә башлагач, русча укысыннар. Бу гына телне какшатмый. Әгәр син аны беләсең икән, онытмыйсың. Районда телне саклар өчен күп эш башкарыла. Тукай ягы булуыбыз, телне кадерләп саклавыбыз белән горурланам.

Фирдүс ТЯМАЕВ,
Татарстанның атказанган артисты:

– Татар булуым белән бик горурланам. Мин бу хакта күкрәк киереп кычкырып сөйлим, җырлыйм. Шөкер, быел күп эшләнелде. Үзбәкстанга барып, андагы татарлар белән күрешеп, аларның күңелен рухландыру өчен җырлап кайттык. Мордовия өлкәсендә узган Бөтенроссия Сабан туенда катнаштык. Кайда да «Татарлар» җыры яңгырады. 4 көн рәттән Бөтендөнья татар конгрессының VIII съездында катнашам. Мин – үз илемнең, телемнең патриоты. Башкаларга да шуны телим. Кайда гына чыгыш ясасам да, яшьләргә татар булуыннан оялмаска кушам. Киресенчә, мин – татар, дип күкрәк киереп йөрергә кирәк. Модага ияреп, вата-җимерә русча сөйләшү эшмени ул? Үз телен санлаган, данлаган милләтнең генә киләчәге бар.

Сәйдә МӨХӘММӘТҖАНОВА, яшь җырчы:

– Татар җырлары белән мәдәниятебезне Россиядә генә түгел, чит төбәкләргә дә таныту өстендә эшлибез. Башкалар да татар җырын тыңласын, дибез. Зур хыялым бар: татар халык җырларын җыеп, альбом чыгарасым килә. Интернеттан эзли башласаң, халык җырлары бик аз. Шушы хыялымны тормышка ашырырга иде. Үземнең татарча җырлавым, сөйләшүем өчен мин әтиемә рәхмәтле. Безгә гаиләбез белән Екатеринбург шәһәрендә яшәргә туры килде. Шул вакытта татарча сөйләшү кимеде. Әтиебез, телне саклар өчен, безне Казанга кайтарып җибәрде. Миңа калса, һәр гаилә үзенең туган теле турында үзе кайгыртырга тиеш. Мин телне саклауның башка юлын белмим дә. Бары тик гаилә генә ярдәм итә ала.

Финзия ГАЗИЗОВА, Австралиядә яшәүче татар:

– Язмыш кушуы буенча чит җирдә яшәсәм дә, мин Балтач кызы, Татарстанныкы булуым белән горурланам. Әгәр гаиләдә башка телдә сөйләшәләр икән, димәк, ана теленә мәхәббәт шуның кадәр генә! Безнең төп бурыч – телне саклау, аны оныкларга тапшыру. Бу – әманәт. Мактанып әйтмим, безнең балалар татар телендә матур итеп сөйләшәләр. Авылдашларым да шакката. Бу – ирем белән икебезнең тырышлык нәтиҗәсе. Балалар инглиз телендә сөйләшә башлауга, шундук туктатабыз. Өйдә, сәяхәттә бары тик татарча сөйләшәбез. Интернеттан татар әкиятләре тыңлыйбыз. Татар каналын карыйбыз. Ә кичен татар халык әкиятләрен укыйбыз. Үзебезнең тырышлык булса гына, без, телне саклап, мин – татар, дип әйтә алачакбыз.

Беренче адымнар

ТАРИХИ ВАКЫЙГА

Индус ТАҺИРОВ, ТФА академигы, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының беренче, 1992–2002 еллардагы җитәкчесе

Бөтендөнья татар конгрессының барлыкка килүе чын мәгънәсендә тарихи вакыйга булды. Ул тиз арада татар милләтенең халәтен, яшәешенең төп проблемаларын күрә алырдай оешма булып өлгерде. Татарларның кайда яшәүләренә дә карамастан, аларның сулышын сизеп, бер җан, бер тән булып яши башлауларына нигез салды, Татарстанның мөстәкыйльлеген ныгытуга үз өлешен кертте.

Эшчәнлегебезнең иң нәтиҗәле ысулы – башкарма комитет тарафыннан уйлап табылган һәм дөреслеген тормыш үзе раслаган күчмә утырышлар булды. Аның беренче утырышы Түбән Камада үтте. Күчмә утырышларны үткәрү, гадәти хәлгә әверелеп, милли оешмаларыбызның җирле хакимиятләр белән аңлашып яшәвенә юл ачты. Аларның берсенә махсус тукталуны кирәк дип саныйм. Ул 1998 елның 9–10 мартында Санкт-Петербургта, шәһәр губернаторы Владимир Яковлев катнашында булды. Губернатор очрашуыбызның икенче көнендә конгресс әгъзалары белән мәчеткә килде һәм анда сугыш вакытында зарарланган манараны торгызуда ярдәм итәчәген әйтте. Аның ярдәме белән Казанның иске йортлардан торган Свердлов урамы төзекләндерелгәндә һәм шуннан соң ул Петербург урамы дип атала башлады.

Гомумән, без күп губернаторлар белән аралашып яшәдек. Саратов губернаторы Дмитрий Аяцков ярдәме белән шәһәр уртасында татар гимназиясе ачылды. Свердловск өлкәсе губернаторы Эдуард Россель ярдәме белән Урал университетында татар тарихын өйрәнү лабораториясе эшли башлады. Ул конгрессның күчмә утырышында хөкүмәт әгъзалары белән тулы составта катнашты. Шунда ике якның министрлары бергә эшләү турында килешү төзеделәр.

Екатеринбургта, Ульяновскида, Казахстанның Чимкент шәһәрендә, Самара өлкәсенең Камышлы районында узган утырышлар шулай ук уңышлы булды. Кайбер мөһим мәсьәләләр буенча очрашулар Киев, Минск, Уфа, Әстерхан, Иваново, Төмән, Нижневартовск, Чиләбе, Пермь шәһәрләрендә дә оештырылды. Бу чараларда мәгариф, мәдәният, радио-телевидение мәсьәләләре буенча килешүләр төзелеп, кабат очрашкан вакытта аларның үтәлеше тикшерелә торган иде. Конгресс Ульяновск, Оренбург, Новосибирск, Омск губернаторлары, Удмуртия һәм Якутия президентлары белән эшлекле мөнәсәбәттә булды. БДБ илләре шәһәрләрендә оешкан дистәдән артык милли оешмалар белән элемтәдә торды.

Милли хәрәкәтнең үзенчәлеге Россия төбәкләрендә милли-мәдәни мохтарият органнары барлыкка килүдән гыйбарәт. Шунысы сөенечле: шушы автономияләр аркылы милли эшләр башына югары катлау зыялылар килде. Алар татар тормышын үстерүгә зур өлеш керттеләр.

Утыз ел күз ачып йомгандай үтте дә китте. Аны оештыручылар урынына яңа буын барлыкка килде. Алар җиңел булмаган шартларда милләтебезнең киләчәген кайгырталар. Телебезне, динебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калу һәм ныгытуны үзләренең төп бурычы итеп саныйлар. Безнең эшебезне дәвам итәләр.

КОРЫЛТАЙДАН – КОРЫЛТАЙГА

I корылтай (19–21 июнь, 1992 ел)
Бөтендөнья татар конгрессының беренче корылтаена бер меңнән артык кеше җыела. Пленар утырышта Бөтендөнья татар конгрессы карары, дөнья халыкларына һәм дәүләтләренә, Берләшкән Милләтләр оешмасына мөрәҗәгать кабул ителә. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе итеп Казан дәүләт университетының кафедра мөдире, Татарстан Фәннәр академиясе әгъза-мөхбире Индус Таһиров сайлана.

II корылтай (28–29 август, 1997 ел)
Корылтайга Россиянең алтмыштан артык төбәгеннән, ерак һәм якын чит илләрдән барлыгы 459 делегат чакырыла. Мәскәү, Үзбәкстан, Таҗикстан һәм Татарстан кинематографистлары берьюлы берничә документаль фильм төшерә. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе итеп кабат Индус Таһиров сайлана.

III корылтай (28–29 август, 2002 ел)
Бу корылтайда 25 ерак һәм якын чит илләрдән, Россиянең 57 төбәгеннән 562 делегат һәм мәртәбәле кунаклар катнаша. Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты рәисе итеп «Казан» милли мәдәният үзәге директоры Ринат Закиров сайлана.

IV корылтай (12–15 декабрь, 2007 ел)
Корылтай эшендә 712 делегат, 217 шәрәфле кунак катнаша. Пленар утырышта Бөтендөнья татар конгрессының татар халкына, Россия Президенты Владимир Путинга мөрәҗәгате, татар һәм башкорт халкына мөрәҗәгатьләре кабул ителә. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе итеп кабат Ринат Закиров сайлана.

V корылтай (6–9 декабрь, 2012 ел)
Корылтайда Татарстаннан, Россия төбәкләреннән, якын һәм ерак чит илләрдән 796 делегат, 302дән артык шәрәфле кунак катнаша.
Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты әлеге чараны үзенең интернет сайтында онлайн режимда трансляцияләүне оештыра. Пленар утырышта, татар халкының алга таба үсеш юлларын билгеләү ниятеннән, «Татар халкының этник үзенчәлеген саклау концепциясе» проекты тәкъдим ителә.
Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты рәисе итеп кабат Ринат Закиров сайлана.

VI корылтай (2–6 август, 2017 ел)
Корылтайда Татарстаннан, Россиянең 73 төбәгеннән һәм 41 ерак һәм якын чит илләрдән 811 делегат килә. Россия Президенты Владимир Путин корылтай кунакларына котлау телеграммасы юллый. Корылтай делегатлары берничә көн буена татар телен, мәдәниятен, рухи мирасны саклау, эшмәкәрлекне үстерү мәсьәләләре турында сөйләшәләр.
Пленар утырышта төп вакыйга Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шурасын оештыру була.

VII чираттан тыш корылтай (20–21 июль, 2018 ел)
Бу корылтайның көн тәртибендә Бөтендөнья татар конгрессы уставына үзгәрешләр кертү карала. Чарада Россиянең 60 төбәгеннән – 200, чит илләрдән 25 вәкил катнаша. Корылтайның пленар утырышын Татарстан Премьер-министры Васил Шәйхразыев алып бара. Ул 2017 елда VI корылтайда кабул ителгән Милли Шура уставын теркәү барышында Россия Юстиция министрлыгы тарафыннан җитешсезлекләр күрсәтелүен әйтә. Шул сәбәпле чираттан тыш корылтай үткәрергә кирәк була. Уставка төзәтмәләр кертелгәннән соң, делегатлар Милли Шура рәисе итеп Васил Шәйхразыевны сайлыйлар. Шуннан соң рәис устав нигезендә үзенең беренче урынбасары итеп Башкарма комитетның ул вакыттагы җитәкчесе Ринат Закировны билгели.

ДӨНЬЯ БЕЗГӘ КАРАП СОКЛАНСЫН

Тәэминә БИКТИМИРОВА, 1992–1997 елларда Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты әгъзасы

Бөтендөнья татар конгрессының беренче корылтае ачылган көн һәр татар өчен зур вакыйга булды. Икенче көнне, ягъни 20 июньдә эшебез «түгәрәк өстәл»ләр янында дәвам итте. Барысы 15 секция иде. Минем өлешемә «Милләт, хатын-кыз һәм гаилә» секциясендә катнашу бәхете тиде. Җитәкчесе «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Роза Туфитуллова булды. Зур дулкынлану белән Актерлар йортына җыелдык. Залда иң зур хөрмәткә ия кунаклар – өлкән язучыбыз Гомәр ага Бәширов, сөекле җырчыбыз Фәридә апа Кудашева, хөрмәтле абыстайларыбыз Рәшидә Исхакый, Сәйдә Аппакова, ерак араларны якын итеп килгән Шәмсия Апакай, Нәркиз Агиш…

Анда сөйләнгән сүзләр бүген дә хәтеремдә. «Әйдәгез, татар хатынының бөтен матур сыйфатларын бөтен дөньяга танытыйк, – дигән иде галимә Мәдинә апа Рәхимкулова. – Элек күрсәтә алган бит татар хатыны үзенең матурлыгын, гыйлем-мәгърифәтле булуын, гаиләсенең тоткасы һәм балаларына оста тәрбияче булуын. Дөнья безгә карап соклансын, үрнәк итеп куйсын татар хатынын».

Секция утырышында татар хатын-кызларының иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген җанландыру, татар теленең кулланыш даирәсен киңәйтү, милли гореф-гадәтләрне, йолаларны саклау, татар гаиләсенең яшәеш сферасын киңәйтү һәм аны милли рухта коруга булышлык итүгә юнәлдерелгән бер адым ясалды – Бөтентатар хатын-кызлар берләшмәсе оештырылды. Берләшмәнең советы, идарәсе булдырылды. Урыннарда берләшмәнең бүлекчәләрен оештыру максаты куелды. Күренекле галимәбез Флора Әхмәтова-Урманче тәкъдиме белән берләшмәгә «Ак калфак» исеме бирелде.

«Ак калфак»ның үз заманында халкыбыз күңеленә кереп калырдай эшләре аз булмады. Шул җәһәттән, асылыбызга кайтыр өчен, мең еллык тарихыбызны каныбызга сеңдерер өчен, гаиләдә, мохитебездә хатын-кызның дәрәҗәсен күтәрү өчен оештырылган «Гыйффәт туташ», «Киленбикә» кебек чараларның әһәмиятен аерым күрсәтеп үтәсем килә.

Безнең эш күбрәк йомышы төшеп килүчеләрне кабул итү, мөмкин кадәр аларга ярдәм итү һәм конгрессның төрле төбәкләрдә бүлекләрен булдыруга булышу белән бәйле иде. Бәхетебезгә, төбәкләрдә татар иҗтимагый үзәкләре оешкан һәм милләтпәрвәрләребез аларда тупланган иде. Төбәкләрдән килүчеләр төрле булган кебек, йомышлары да төрле булып, еш кына уңайсыз хәлләрдә дә кала идек. Бөтендөнья татар конгрессы булсак та, баштагы мәлдә акчабыз юк иде бит әле.

Командировкадан кайтып кермәдек, дип әйтә алам. Мин үзем Минскидан Иркутскига кадәр бөтен төбәкләрне иңләдем. Башкалар да шулай йөрде. Кулдан килгәнне дә, килмәгәнне дә эшләргә тырыштык. Барып кергән җиргә татар гадәте буенча ниндидер күчтәнәч алып барасы килә иде. Әмма, әйткәнемчә, акча юк. Иваново губернаторы янына 14 сумлык курай тотып кереп, бүләк итеп чыктым. Шул хәлдән бүген дә уңайсызланып куям.

Хәзер конгресста эшләүчеләргә сокланып та, көнләшеп тә карыйм. Акчалары да бар, эшләре дә масштаблы. Тагын да шулай матур эшләре белән сөендерсеннәр иде. Тик кайберәүләрнең бу эшләргә тискәре бәя бирүләрен күреп кенә эчем поша. Хәтта Сабантуй үткәрү дә телгә начар яктан кергәли. Югыйсә бу бәйрәмебез бик югары бәяләнеп, татарларны дөньяга танытты бит. Күбрәк белгән кеше тәнкыйтьләп кенә йөрмәсен, оешмага тәкъдимнәр белән килсен иде ул. Бөтендөнья татар конгрессына да, аның матур эшләренә дә уңышлар телик.

30 ЕЛЛЫК ЮЛ

Ринат ЗАКИРОВ, 2002–2020 елларда Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе

Утыз ел гомер эчендә Бөтендөнья татар конгрессы зур юл үтте. Шушы чорда татар дөньясы Татарстан белән бер дулкында яшәүгә иреште. Бүген дөньяның 42 илендә, Россиянең 70тән артык төбәгендә татарның 458 милли һәм дини оешмасы эшли, үзара хезмәттәшлек итә. Кайсы гына өлкәне алма – мәгарифме, фәнме, спортмы, икътисадмы, авыл хуҗалыгымы – һәр тармакта милләттәшләребез үзләрен иң яхшы яктан күрсәтә.

2002 елда, конгрессның III корылтаенда мине башкарма комитет рәисе итеп сайладылар. Аңлавымча, безгә системалы, киң күләмле хәрәкәт кирәк иде. III корылтайда күп кенә делегатлардан татар яшьләрен милли хәрәкәткә җәлеп итү турында фикерләр яңгырады. Алар арасында чит төбәкләрдәге һәм чит илләрдәге татар яшьләрен Татарстан югары уку йортларында укыту мәсьәләсе дә бар иде. Без исә киңрәк бурыч – татар дөньясындагы үзебезнең оешмаларга бәйле аерым яшьләр хәрәкәтен оештыруга алындык. Нәкъ шул вакытта махсус татар яшьләре оешмалары барлыкка килде, аларның саны 50дән артты.

Мәгариф өлкәсендә махсус программа булдыруга ирештек. Ел саен читтә яшәүче йөзләгән татар баласы республика югары уку йортларына укырга керә башлады. Бу проект чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез өчен бигрәк тә кулай булып чыкты. Әйтик, Кытайдан чыккан 100дән артык татар яшьләре төрле елларда Казан югары уку йортларында уку бәхетенә ирешә. Яшьләр белән тыгыз элемтәдә эшли башлагач, бу эшчәнлекнең төп оештыручысы кирәклеге ачыкланды. Шулай итеп, без 2004 елда беренче Бөтендөнья татар яшьләре форумын уздырдык.

Дин өлкәсендә дә шактый катлаулы проблемалар булуы ачыкланды. Иң мөһиме бердәмлек булмавы үзен нык сиздерә башлаган иде. Шуны аңлап, БТК дин әһелләрен аралаштыру өчен бер мәйданчык булдырырга алынды. «Изге Болгар җыены» дип аталган яңа чара гамәлгә куелды. Бүген инде бу чарага төрле җирләрдән меңләгән кеше килә. Төбәкләрдә татар имамнарына мохтаҗлык зур. Шуны аңлап, без Казандагы Россия Ислам институты белән дә хезмәттәшлек итә башладык.

Соңгы елларда татар тормышының иң авырткан мәсьәләсе – татар авыллары яшәеше. Кайбер татар авылларының тәҗрибәсе белән танышканнан соң, без аны башкаларга да таратырга кирәк дигән фикергә килдек. Шулай итеп, 2012 елның язында I Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре форумы узды. Шушы нигездә Бөтенроссия татар авыллары оешмасы барлыкка килде.

БТКның Сабантуй бәйрәмнәре, фольклор фестивальләре, «Татар кызы» конкурслары, җыр фестивальләре кебек мәдәният, халык традицияләренә кагылган проектлары турында да әйтеп үтәргә кирәк. Шушы чаралар нигезендә күпчелек төбәкләрдә дистәләгән иҗат коллективлары барлыкка килде. Татар халкын берләштереп торучы төп чара – Сабантуй. Чит илләрдә дә бу бәйрәмне үткәрү гадәткә керде.

Татар конгрессы өчен ул елларда Башкортстандагы татарларның мәнфәгатьләрен хәл итү иң четерекле мәсьәлә булып торды. 2002 елның декабрендә халык санын алу чарасы мәсьәләне тагын да катлауландырды. 2007 елгы IV корылтайга әзерләнгәндә, без мондый каршылыкны туктатырга кирәк дигән фикергә килдек. Нәтиҗәдә махсус мөрәҗәгать кабул ителде. Ниһаять, вазгыять шактый йомшарды: Башкортстанда Татарстан телевидениесен карый башладылар, ике республиканың иҗат коллективлары янә бер-берсенә гастрольләргә йөри башлады.

Мин җитәкчелек иткән чорда Мәскәүдә Халыкара Россия ватандашлары оешмасы барлыкка килде, безнең конгресс аны оештыручыларның берсе булды. Нәтиҗәдә Тышкы эшләр министрлыгының «Россотрудничество» оешмасы аша чит илләрдәге татарлар мәнфәгатьләрен андагы илчелекләр аша яклау мөмкинлеге ачылды. 2013 елда Европа парламенты бинасында Европа татарлары альянсының (АТА) оештыру җыелышы узды, ул җыелыштан соң әлеге оешма Бельгиядә рәсми теркәлү узды. Шуның аша андагы татарларга мәдәни чаралар уздырганда төрле халыкара оешмалар ярдәменә таяну мөмкинлеге ачылды. Конгресс эшчәнлеген илнең Тышкы эшләр министрлыгы да югары бәяли. Россия ватандашларының халыкара җыеннарында тышкы эшләр министры Сергей Лавров һәрвакыт Бөтендөнья татар конгрессының эшчәнлеген башкаларга үрнәк итеп куя. Бу – Татарстан Республикасы өчен дә зур дәрәҗә.

БҮГЕН ВАЗГЫЯТЬ БАШКА

Разил ВӘЛИЕВ, 1992–2002 елларда Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчесе урынбасары, 2002–2012 елларда Мәдәният комиссиясе рәисе

Узган гасырның 80 нче елларында татар халкы арасында милли хәрәкәт активлашып китте. Халыкның милли аңы үсә башлады. Илдәге демократия җилләре аның өчен шактый гына мөмкинлекләр тудырды. Бу активлашуның кульминацион ноктасы буларак 1990 елның 30 августында Татарстанның дәүләт бәйсезлеге турында декларация кабул ителде. Шуннан соң инде башка бик мөһим сәяси вакыйгалар да булды: Конституция кабул ителде, референдум үткәрелде. Әмма аңа кадәр, 1992 елның башында, Беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең Бөтендөнья татар конгрессын оештыру турындагы фәрманы чыкты. Мондый оешма ни өчен кирәк булды? Бу хакта төрле фикерләр бар. Берәүләр аны иҗтимагый оешмаларга көндәш буларак кабул итсә, икенчеләр милли хәрәкәтнең эшчәнлеген дәүләт мөмкинлекләрен файдаланып алып баруда күрделәр. Чыннан да, иҗтимагый оешмалар үз эшләрен эшлиләр, ул заманда алар бигрәк тә актив эшләделәр. Әмма дәүләт ярдәменнән башка алга куйган зур максатларга ирешү, бөтен дөньяга сибелеп яшәгән татар халкын берләштерү мөмкин түгел иде, монда дәүләтнең барлык мөмкинлекләрен дә файдалану кирәк булды.

Шулай итеп, 1992 елда конгресс оешты. Милли оешмалар да үз эшләрен дәвам иттеләр. Безнең бурычларыбыз бер, максатларыбыз уртак иде: татар халкының сәяси һәм икътисади мөмкинлекләрен арттыру, аның дәүләтчелеген ныгыту, туган телне, милли мәгарифне, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне саклау һәм башкалар. 1992 елның 19 июнендә конгрессның беренче корылтае үткәрелде. Мин корылтайларның һәрберсендә катнаштым, кайберләрендә чыгыш ясарга да, секцияләрне җитәкләргә дә туры килде. Ул чорда мөмкинлекләр башкачарак, зуррак иде. Нәкъ шул елларда милли мохтариятләр булдыру турында Россия күләмендә закон чыкты. Шуңа нигезләнеп, татар халкының да федераль дәрәҗәдәге милли автономиясе барлыкка килде. Һәм шунысы үзенчәлекле: ул елларда милли мохтарият белән конгресс берләшеп эшләделәр. Аларның икесенә бер уртак җитәкче – атаклы галим, академик Индус ага Таһиров булды. Бу бергәлекнең көче зуррак кебек тоела иде безгә. Ике көчле оешма. Аның берсе федераль закон белән расланган, икенчесе – Татарстан Президенты Указы белән. Индус ага бу мөмкинлекләрдән бик оста файдаланды. Мин ул вакытта Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары идем. Индус Таһировның эш стиле, дәлилләре, чыгышлары күңелемә һәрчак якын булды. Ул чорда читтә яшәүче милләттәшләребез янына күп йөрдек. Кайсы гына төбәккә барсак та, Индус ага иң зур җитәкчеләр белән очрашырга җай тапты. Анда яшәүче татарларның проблемаларын бик оста итеп җиткерә, фәнни дәрәҗәдә дәлилле итеп аңлата белде. 1994 елда Россия белән Татарстан арасында вәкаләтләр бүлешү турында беренче шартнамә кабул ителде, монда да Индус аганың роле бик зур иде. Ул татар халкының, аның дәүләтчелегенең тарихын яхшы белә. Россия делегацияләре белән аралашкан вакытта аның саллы чыгышлары һәрчак нәтиҗәле булды.

Әйтергә кирәк, конгресс эшчәнлегенә кагылышлы традицияләр хәзер дә дәвам итә. Әмма бүген инде сәяси вазгыять тә, мөмкинлекләр дә башка. Конгрессның структурасында да үзгәрешләр булды. Элек аның башкарма комитеты гына бар иде. Хәзер карарлар чыгаручы югарырак оешмасы – Милли җыены да барлыкка килде. Ул күбрәк идеология белән шөгыльләнә, эшчәнлеккә юнәлеш бирә, стратегия документлары, концепцияләр әзерли, максатларны билгели. Башкарма комитет исә шушы Милли җыен кабул иткән карарларны тормышка ашыру белән шөгыльләнә.

ӨМЕТЛӘР АКЛАНДЫ

Ренат ХАРИС, Татарстанның халык шагыйре, Россия Федерациясе Дәүләт премиясе лауреаты

Бөтендөнья татар конгрессының идея һәм концепция авторы буларак, 30 ел элек булган хәлләр бүгенгедәй күз алдымда. Ул вакытта мин «Татарстан хәбәрләре» дип аталган парламент газетасының баш редакторы, Татарстанның Югары Советы депутаты (ул вакытта безнең парламент шулай атала иде), мандат комиссиясе рәисе идем. Казан Кремлендә, Югары Совет бинасындагы бер бүлмәдә безнең редакция коллективы әле оешып кына килә. Гаҗәеп кызыклы һәм киеренке еллар иде бу, чөнки параллель рәвештә Бөтендөнья татар конгрессы да оеша башлады. Ул дөньяның төрле почмакларына сибелеп яшәгән татарларны милләт, халык булып берләштереп торырга дигән ният белән төзелде. Татарстанда яшәүче татарлар дөньядагы барлык татарларның мәнфәгатен күз уңында тотып, аларга таянып, ә читтә гомер итүче милләттәшләребез безгә таянып, ярдәмләшеп гомер итәргә тиешләр. Шул чагында гына безнең киләчәгебез, язмышыбыз имин булачак.

Эш барышы болайрак булды. 1991 елның март – апрель айлары. Мин булачак оешманың концепциясен, нигезләмәсен эшләдем. Ул вакытта Дәүләт Советында аппарат җитәкчесе Хәләф Низамов иде. Документларны аңа күрсәттем. Ул мине Югары Совет рәисе Минтимер Шәрипович Шәймиев янына алып керде. Минтимер Шәрипович, гадәттәгечә, мәсьәләгә бик җитди карады, төрле яктан килеп фикер йөртте, бәхәсләште, аның нинди сәяси проблемалар тудырачагы турында ачыктан-ачык уйланды. Ул да Җир шарының төрле кыйтгаларында яшәүче татар милләтен тарихи туган җирләре белән элемтәдә тотучы көч кирәклеге турында күптән уйлана икән. Кыскасы, ул аны хуплады. «Әйдәгез, оештырабыз, моның өчен оештыру комитеты булдырырга кирәк, тиз арада исемлек китерегез», – диде. Ул вакытта Югары Советның юридик бүлеген Рәисә Сәхиева җитәкли иде. Без өчәүләп – Хәләф Низамов, Рәисә Сәхиева һәм мин – конгрессның оештыру комиссиясен төзедек, иң беренче документларының проектларын әзерләдек. Конгрессның беренче корылтае 1992 елда булды. Ул вакытта Минтимер Шәймиев Татарстан Республикасының Президенты иде инде.

Әйтергә кирәк, конгресс төзү идеясе тикмәгә генә тумады. Бөтен яктан да киеренке ул заманда Татарстан Конституциясен төзү буенча комиссия эшләде. Аның җитәкчесе Президентыбыз Минтимер Шәймиев иде. Мин – шул комиссия әгъзасы, «Татарстан дәүләт символлары» һәм «Республикабыз башкаласы» дигән маддәләр өчен җавап бирәм. Бу хакта соңрак китап та яздым. Ул татар, рус һәм инглиз телләрендә басылып чыкты. Төп Законны эшләү барышында республика, аның киләчәге, халкы турында уйланасың. Татарстанда татарларның 25 проценты гына яши, 75 проценты читтә гомер итә. Ә без Төп Законны кем өчен кабул итәбез? Татарстанда яшәүче татарлар өченме, әллә инде бөтен дөньяда таралып яшәүче татарлар өченме? Әлбәттә, безнең уебызча, ул бөтен татар өчен булырга тиеш иде. Татарстан Республикасы Конституциясендә соңрак «Республикада яшәүче халык, дәүләтебез Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребезгә ярдәм күрсәтергә тиеш» дигән маддә дә барлыкка килде, ягъни конгресс идеясе республикабызның Төп Законы белән ныгытылды, гамәлгә кертелде.

Бөтендөнья татар конгрессын төзү турындагы указга Минтимер Шәймиев имза куйды. Без аннан: «Бу оешманың җитәкчесе сез булырга тиеш түгелме?» – дип сорадык. «Юк, – диде ул. – Минем эшем республика чикләрендә кала. Монда шундый кеше кирәк: ул бөтен татар халкына билгеле дә, теоретик яктан әзерлекле дә булсын, татарча да, русча да яхшы белсен, башка телләрне белсә дә бик әйбәт. Менә шундый абруйлы кеше эзләп табыгыз», – дип күрсәтмә бирде. Уйлый торгач, иң беренче рәис итеп академик Индус Таһировны тәкъдим иттек. Һәм бу кандидатураны беренче корылтай бертавыштан кабул итте.

«Конгресс өметләрне акладымы?» дигән сорауны еш бирәләр. Әлбәттә, заклады. Тик замана үзгәрә. Аның белән бергә конгресска да, республикага да, милләтләргә дә таләпләр үзгәрә. Шул таләпләргә җавап бирә-бирә, конгресс үзенең эшен үзгәртә торды. Иң мөһиме – татарны, республикабызны, мәдәниятебезне, тарихыбызны башка халыкларга күрсәтү-таныштыру. Әгәр халыклар бер-берсен белмәсә, бер-берсен аңламаса, дус яши алмый, ә дуслыкның булмавы илнең нигезен какшата. Аны икътисад кына саклап кала алмый. Кайда гына яшәсә дә, татар беркайчан да шул төбәктә, илдә-дәүләттә ыгы-зыгы чыгармады, матур итеп яши белде, һәм алда да шулай булачак. Безнең конгрессыбызның да төп максаты – милләтебезне берләштереп, аңа башка милләтләр арасында үзенең лаеклы урынын тотарга ярдәм итеп, Россия дәүләтчелегенең нигезен ныгыту.

Мөнәсәбәт

МИЛЛӘТ ҖЫЕНЫ: НИЯТЛӘР ҺӘМ ГАМӘЛЛӘР

Дөнья илләрендә яшәгән татарлар сигезенче корылтайга җыела. Тагын бер тапкыр. Иң беренче съезд әле дә күз алдында. 30 ел үтеп китсә дә, ул кичә генә булган кебек. Шул ук Казан, Җәлил театры, шул ук Ирек мәйданы. 1992 елның 19 июне кояшлы көн иде. Мин, делегатларга ияреп, залга кереп утырмадым. Оештыру төркеме вәкиле буларак, Җәлил театры залына кунакларны керттем дә яңадан мәйданга чыктым. Анда татарча музыка яңгырый, театр алды мәйданында билгеле кешеләр, республиканың иң зур җитәкчеләре дә биюгә катнашып китә. Бернинди сценарийда язылмаган тамаша.

«Татар-информ»

Әлбәттә, бу көнне алдан уйланган сүзләр, гамәлләр, ихлас елмаюлар да күп булды. Тантаналы рәсми сүзләр бу юлы татарча яңгырады. Элекке Офицерлар йорты, хәзерге шәһәр Ратушасының (бер гасыр элек анда Дворянское собрание утырган) түбәсендәге колонкалардан яңгыраган татар көйләрен конгресс ачылышы трансляциясе алыштырды. 1917 елның 22 июлендә нәкъ шул бинада дини, милли, хәрби Шураларның уртак корылтаенда Россия мөселманнарының милли-мәдәни автономиясе төзелгәнлеген беләбез. Менә шул матур бина ягыннан татар конгрессының беренче съезды авазлары ишетелгән иде. Бүген дә шул көнне әйтелгән сүзләр колакта яңгырый.

Менә оештыру комитеты рәисе Мөхәммәт Сабиров президиум сайлата һәм беренче зур чыгыш өчен Минтимер Шәймиевкә сүз бирә. «Ниятебез изге, юлыбыз туры» дип аталган бу нотык хәзер дә онытылмаган һәм искермәгән. Ачылыш тантанасын да, Беренче Президент чыгышын да шул мәйданда аягүрә килеш дулкынланып тыңлыйм. Залга кереп тору кая! Башкача мөмкин дә түгел, эссе һәм хисле, киеренке залда йөрәк чыдамас иде кебек.

Чөнки тарихта беренче тапкыр шундый җыелу, шундый сүзләр, карарлар, проектлар яңгырату беркайчан да булмаган. Татар халкының язмышы, гасырлар аша хәзерге көнгә килеп җитү турында сүзләр татарча, иң югары мөнбәрдән ишетелде…

Сез, мөгаен, бу сүзләрне төзәтерсез, моңа кадәр булган зур җыеннарны, хан яки мөфти сайлауларны, Бөтенроссия мөселман корылтайларын, милли хәрәкәт җыеннарын искә алырсыз. Батый ханнар, Олуг Мөхәммәтләр һәм башка патшалар үткәргән җыеннардан башлап, узган гасыр башындагы Мәскәү, Петербург, Түбән Новгород, Казан мөселманнары корылтайлары, хәтта Бөтенроссия милли-мәдәни мохтарияте турында әйтерсез.

Хәтта Садри Максуди, Заһир Бигиев, Гаяз Исхакыйлар җитәкчелегендә 1917 елның маенда Мәскәүдә Әсәдуллаев йортында 900 делегат катнашында үткән Россия мөселманнары корылтаенда да татар халкының бөтен төбәкләре, катлаулары исеменнән милләт язмышын тикшергәннәр дип әйтеп булмый. Анда февраль инкыйлабы, патша төшерелгәч, Россия язмышы каралган.

Татар мәсьәләсенә тыныч, конструктив, төпле караш булдыру беркайчан җиңел булмагандыр. Хәтта ТАССР төзелеп, социалистик милли мәгариф, мәдәният булдырган совет чорындагы җыелыш-декадаларда да милли тарихлар искә алынмый иде. Аларда катнашучыларның составы, географиясе, төрле катлаулардан сайланып килүе Бөтендөнья татар конгрессы съезды белән тиңләшә алмас иде. 1917 елдагы «Дини Шура», «Милли Шура» яки «Хәрби Шура» белән татар җыены арасында аерма зур. Мөселман съездлары делегатларының 90 проценты татар булса да, махсус татар җыены түгел иде алар.

> Безнең заманда милләт турында ачык сөйләшү форсаты туды. Татар җыенында катнашкан түрәләр, генераллар, зур эшкуарлар да, «гади» укытучылар, тракторчылар да, әгәр дә алар татар булсалар һәм милләт мәнфәгате турында кайгыртсалар, шул ук залда мандатларын күтәреп тавыш бирә яки тәкъдим кертә алалар. Моның өчен аларның сайлану, җыелу тәртибе гамәлдәге кануннар буенча хәл ителергә тиеш.

Без яшәгән чорда милли хәрәкәтне күтәргән шәхесләр, алар сайлаган Милли Мәҗлесләр, Милли Идарәләр дә һич рәнҗемәсен. Аларның җыелу, сайлану тәртипләре татарлар күпләп яшәгән Россия һәм Татарстан кануннары белән килештерелмәгәч, бу ниятләр гамәлгә керә алмаслар иде. Безгә бөтен халык һәм дәүләт тарафыннан да таныла торган җыелыш һәм гамәли оешма кирәк иде. Татарлар яшәгән дәүләтләргә һәм халыкара хокук нормалары кысасына сыеп эшли торган оешма ихтыяҗы туды. Татар конгрессы шундый булырга тиеш. Нәкъ шундый җыенда делегатлар татар халкы исеменнән Татарстанны яклап, аның татар милләтенә кирәклеген өздереп әйтте. Һәм татар конгрессының хокукларын, легитимлыгын инкарь итү мөмкин түгел иде.

Минтимер Шәймиев беренче съезд ачылышында татар милләтенең гаять катлаулы һәм фаҗигале тарихы, хәзерге заманда милли яшәү рәвеше турында сөйләде. Китерелгән аргументлар бәхәссез иде.

Менә 30 ел иде татар конгрессы милли үсеш, туган телне, мәдәниятне саклау миссиясе юлыннан бара. Татар мохитендә мәгърифәт, мәдәният, фән һәм матбугат эшләрен алып барганда, Татарстан мөмкинлекләре эшкә җигелә. Татарның тәрәккыяте милли-мәдәни оешмалар һәм Татарстандагы гуманитар үзәкләр, милләттәшләр яшәгән төбәкнең хакимият органнары, башка милләттәшләр белән хезмәттәшлегенә бәйле.

Яшьләрне гореф-гадәтләргә, мәдәняткә җәлеп итү бүген дә гомумтатар оешмасының төп бурычы булып кала. 32 ел элек, СССР үзгәргән чакта, яңа Россия дәүләте төзелгәндә, Татарстан Республикасы тигез хокуклы субъект буларак, федерацияне гамәлгә кую максаты белән Декларация кабул иткән иде. Шул хокукны яклап, референдум үткәргәннән соң, татар конгрессы җыелгач дөньяга килгән татар балалары хәзер мәктәпкә йөри. Бу конгресс турында аларның әти-әниләре дә ишетеп кенә белә. Хәзер тормышка аяк баскан буынның ният-гамәлләре нинди булыр соң? Кирәкме аларга тел һәм милләт? Аңлыймы алар безнең җырларны? Концерт-спектакльләргә йөриме, без үткәргән Сабантуйларда катнашамы? Гомумән, глобализация һәм сәяси мохит дөньяны үзгәрткән чорда бүгенге татарлар кая таба бара?

Хәзерге шартларда рухи-мәдәни тормышка, гыйлем-мәгълүмат алуга интернет, компьютер, кесә телефоны тәэсире һәм кибет бәяләре, байлыкка омтылу, акча эзләү ниятләре алга чыга.

Быел җыелган сигезенче корылтайниләр хәл итәр, дип көтеп торучылар да бардыр. Яңа заман элекке сорауларны яңача итеп куя. Милләтне саклауда, телне, мәдәниятне яшәтүдә булган мөмкинлекләрдән файдалана беләбезме? Шәһәргә күчеп яши башлаган «урбан-татар»лар милли тәрбиянең, туган телнең кадерен беләме? Телне мәктәптә һәм мөстәкыйль рәвештә, репетитор яки интернет ярдәмендә өйрәнү мөмкинлеге барлык татарларга аңлашыламы икән? Балаларыбызны «Шаян ТВ» каналын карарга өйрәтәбезме? Яшьләребез нинди гәзит-журналлар укый, интернетның нинди сәхифәләрен карый? Татар төбәкләрендә милли оешмаларның интернет битләре ачылганмы, челтәрдә, матбугатта милләт турында мәгълүмат җитәрлекме? Matbugat.ru, «Татмедиа Junior», «Ютуб-татарочки» кебек проектларга иярүчеләр, аларны узып китәргә тырышучылар күренми. Цифрлаштыру елында милләттәшләр арасында онлайн элемтәне көчәйтәсе, интернетның үзен милли эшкә җигү өчен нидер эшлисе бит…

> Көндәлек тормышта туган телне куллану, сибелгән татарны глобаль челтәр ярдәмендә туплау, тарих-мәдәният белән кызыксыну үзебезнең нияткә бәйле. Әйтик, татар белән татарга туган телдә сөйләшергә нәрсә комачаулый? Телне белмәү, диярсез. Ә туган телебезне ярыйсы ук белүче ике татарга туган телдә сөйләшергә, татарча радио-телевидение кабызырга кем комачаулый соң? Татар белән татар үз телендә сөйләшсен, туган тел иркен кулланылган чараларга йөрсен дигән теләк һәм ниятне каян гына аласы? Яшьләр бер-берсен күрсен, сәхнәдә, дәрестә, хезмәт урынында, интернетта танысын, әйдә!

Үз милләтеңнән булган килен яки кияү, бала-чагалар, оныклар милли гореф-гадәт, тәрбия мохитендә үссен. Башка милләт вәкиле белән гаилә корганда, бер-береңне таныту, кирәк кадәр мәдәни традицияләргә өйрәтүдә җәмәгатьчелек тә үз сүзен әйтә алыр иде. Моның өчен татар конгрессы тарихы буенча диссертацияләр, хатирәләр китабы язылырга, беренче съездлар турында документаль фильмнар төшерелергә тиештер. Милли хәрәкәт, мөһаҗирләр, татар конгрессы музее булмау гаҗәпләндерә. 20–30 ел элек, видеопленкалар җитмәү сәбәпле, оператив телерепортажларның сөртелеп барган булуы аяныч!

Тагын нәрсәләр бар? Этнопедагогиканың матур җимешләрен күреп алып, аларны хуплау, зурлау. Милли тәрбия җитмәгән яки уңышсызлыкка очраган чакларда ниндидер нәтиҗә ясау, тормышны үзгәртү. Берәр төрле бәхетсезлек очрагы булса, татар кешесенә бәйле җинаять эшләнсә, кайгыга төшәм. Гадәттә милли тәрбия алган, иманлы гаиләләрдә андый кешеләр үсми.

Хәзер коммерцияле булмаган оешмалар (НКОлар) Татарстанда гына да 5 меңнән артык. Алар өчен грантлар бүленә, конкурслар оештырыла. Шундый грантлар алу өчен проектлар әзерләү милли оешмалар өчен дә мөһим күрсәткеч булыр иде! Кыскасы, Татар конгрессы съездында җитди ниятләр турында сөйләшү мөмкинлеге бар. Иншалла, бу җыен да хәтердә калыр, милли тормышка уңай үзгәрешләр кертер дип ышанам.

Римзил ВӘЛИЕВ,
журналист, 1992–2002 елларда
Бөтендөнья татар конгрессы
Башкарма комитеты рәисе урынбасары

Татар, алга!

Караңгы төсләрне тарата,
Офыкта кызарып таң ата.
Йоклама, татарым,
Сагына ватаның.
Без монда чит түгел, бу җирдә
Торып чык йокыңнан, тор, әйдә.
Чакыра безне таң,
Татарым, тор, әйдә!

Ярсу йөрәк безнең тәндә,
Чиксез куәт безнең җанда.
Тарих ага безнең канда
Татар, алга, алга, алга!

Кояшның батырлык нурлары –
Татарның тарихи юллары!
Без суда һәм җилдә, без исән бу җирдә!
Без монда чит түгел, бу җирдә,
Әләмең тибрәлсен күкләрдә.
Чакыра киләчәк,
Татарым, тор, әйдә.

Булат ИБРАҺИМ

Хуш киләсез!

Альберт АСАДУЛЛИН,
РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисты (Санкт-Петербург):
– Мин – бик бәхетле кеше. Моннан 30 ел элек Бөтендөнья татар конгрессы оешты. Һәм шул вакыттан бирле мин аның делегаты булып торам. Шундый зур оешманың бер өлеше булачагымны белгәч, шундый сөенгән, горурланган идем. Бу хисләр елдан-ел артты гына.

Бөтендөнья татар конгрессы ул – халкыбызның имин киләчәген кайгыртучы куәтле, зур көч. Милләтебез һәм аның киләчәге турында көн саен уйлаучы һәркемгә бик рәхмәтле мин. Барлык милләттәшләремә сәламәтлек, иминлек һәм безнең көчле, талантлы халкыбызга зур ышаныч телим!

Венер МӨХӘММӘТГӘРӘЕВ,
М. Громов исемендәге институтның очучы-сынаучысы (Мәскәү):
– Минем өчен бик кызыклы һәм көтеп алынган вакыйга бу. Бәлки, корылтайда беренче тапкыр катнашуым шулай тәэсир итәдер. Минемчә, рух, тел, фикерләү рәвеше, гореф-гадәт, мәдәният буенча якын кешеләр, милләттәшләр белән очрашу өчен менә дигән мөмкинлек бит бу. Сүз уңаеннан, Татарстан Премьер-министры урынбасары – Татарстанның Россиядәге Тулы вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин белән Мәскәүдә даими очрашып торабыз. Төрле чаралар үткәрәбез, бәйрәмнәр оештырабыз, яшьләр белән эшлибез. Татарстан башкаласында узачак корылтайдан үзем өчен бик күп кызыклы мәгълүмат алырмын дип уйлыйм. Үзем дә милләттәшләребезгә файдалы була алсам, бик шат булырмын. Дөньядагы барлык татарларны берләштерүче Бөтендөнья татар конгрессы корылтае, чыннан да, зур әһәмияткә ия. Чит илләрдә яшәүче күпме милләттәшләребез гореф-гадәтләребезне, мәдәниятебезне сеңдереп, үз сорауларына җавап табып кайтып китә! Мине дә бу зур чараның бер өлеше булырга чакыруларына зур рәхмәт!

Марат ГАЛИӘХМӘТОВ, Татарстанның атказанган артисты (Мәскәү):
– Бөтендөнья татар конгрессының шундый зур, глобаль съезды милләтләрне берләштерә, читтә яшәүче милләттәшләребезнең дәрәҗәсен күтәрә. Аның даимилеген һәм милләт вәкилләрен берләштерүен күрми калу мөмкин түгел. Милләт өчен нәтиҗәсе дә зур. Кызганыч, быел, авырып торуым аркасында, съездда катнаша алмыйм. Узган еллар тәҗрибәсе буенча, шуны әйтә алам: милләтнең үзаңы үсү халәте – бик мөһим. Мондый чаралар үткәрү бөтен халык өчен әйтеп бетергесез зур файда. Быел мин үзем дә М. Җәлил исемендәге Опера һәм балет театры белән актив эшли башладым. Бу – минем өчен зур дәрәҗә. Музыкант буларак мин заманча татар композиторларының уңышка ирешүен күзәтәм. Соңгы вакытта Миләүшә Хәйруллинаның иҗаты белән мавыгам. Күңелемә бик якын. Андыйлар турында күбрәк сөйләргә, күрсәтергә кирәк.

Татарстанның туган телне, музыканы күтәрү буенча зур эшләр башкаруын билгеләп узмый мөмкин түгел. Күпме тырышлык, матди ярдәм күрсәтелә. Александр Сладковский җитәкчелегендәге Татарстан Дәүләт симфоник оркестрына гына карагыз сез! Алар бит иң заманча уен кораллары белән эшли. Оркестр белән дөньякүләм танылган шәхесләр хезмәттәшлек итәргә хыяллана. Бу бит киләчәкне дә кайгырту дигән сүз, чөнки бүгенге композиторларга, сәнгать әһелләренә ярдәм итми торып, милли музыканың киләчәге була алмый.

ДУСЛЫК КҮПЕРЕ

Андрей ГЕРАСИМОВ,
Татарстан Республикасы удмуртларының милли-мәдәни автономиясе идарәсе рәисе:
– Барыбызга да башка милләтләр белән дус булып, бер-беребезне хөрмәт итеп, килешеп яшәү, милләтләребезне саклау өчен тырышырга кирәк. Барыбыз өчен дә уртак эшләр бар: туган телләрне, гореф-гадәтләребезне, мәдәниятне саклау. Бигрәк тә яшьләрне тәрбияләү, алар тамырларыннан купмасын өчен эшләү – барыбыз өчен дә көн кадагындагы мәсьәлә. Дөнья үзгәреп тора, татары да, удмурты да, башкасы да үзгәрә. Татарстан республикада яшәүче барлык милләтләргә зур игътибар бирә. Татарларны хөрмәт итәбез. Бу милләт үзен сакларга тырыша. Тырыша гына түгел, ул моны эшләргә дә тиеш.

Людмила МУСИХИНА,
Казан мариларының милли-мәдәни автономиясе рәисе:
– Татарстанда барлык милләтләр дә дус булып яши. Иң зур казанышларыбызның берсе бу. Узган гасырның 90 нчы елларында ниләр булганын хәтерлибез бит. Хәзерге вакытта Татарстан халыклары ассамблеясы да, Халыклар дуслыгы йорты да әнә шул дуслык какшамасын өчен зур эшләр башкара. Президент каршында телләр комиссиясе татарларны гына түгел, башка милләтләрне дә кайгырта. Әлбәттә, проблемалар да бар. Без – марилар өчен, мәсәлән, тарихыбызны өйрәнү мөһим. Татарлар милли үзаңын саклап калу өчен бик тырыша. Әдәбият-сәнгать, мәдәният мәсьәләсендә зур эшләр башкарыла. Гореф-гадәтләр дә югалмасын иде. Әйтик, милли киемнәрнең заманчалары бар, сәхнә өчен тегелгәннәре бар. Ә борынгы үрнәкләре кайда? Татар дигәч, намуслылык, әдәплелек һәм үҗәтлек кебек сыйфатлар күз алдына килә.

Константин МАЛЫШЕВ,
Татарстан Республикасы чуаш милли-мәдәни автономиясе рәисенең беренче урынбасары:
– Татарга да, чуашка да үзенчәлеген сакларга кирәк. Анысы булса, телне, мәдәниятне дә саклыйсың. Татарстан Хөкүмәте республикада яшәүче татарлар гына түгел, чит төбәкләрдә һәм илләрдә яшәүчеләрне дә кайгырта. Әлбәттә, бу эш үз нәтиҗәләрен бирә. Татарлар кайда гына яшәсә дә, үзен ятим хис итми. Хөкүмәт ярдәме булмаса, бу эшне башкару күпкә катлаулырак булыр иде. Бу сүзләрне белеп әйтәм. Бер елны Латвиягә бу илдә яшәүче татарлар белән очрашуга барырга насыйп булды миңа. Хәтта анда да аларның республика белән элемтәсе барлыгын тоеп кайттым. Ә татар булган җирдә чуашы да табыла. Кая барсаң да, бер тирәдә алар. Миңа калса, татар кешесенә иң элек эшлеклелек сыйфаты хас.

Наталья САБИТОВА,
Татарстан Республикасы мордваларының милли-мәдәни автономиясе җитәкчесе:
– Әлеге җыенда катнашучыларга тотрыклы, имин тормыш, туган телне, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне өйрәнүдә уңышлар телим. Башка халыклар татарлардан үрнәк алып яши. Сезнең телне саклау һәм үстерү өчен ниләр эшләгәнне күреп торабыз. Башкалар да шуны кабатларга тырыша. Әлбәттә, барысы да ал да гөл түгел. Әмма кайсы яктан карыйсың бит. Белгән, күргән кешеләрдән чыгып сөйлим. 1990 нчы елларда татарча сөйләшмәгән, сөйләшергә теләмәгән кешеләрнең балалары арасында бүген туган телендә

kazanfirst.ru

аралашырга тырышучылар еш очрый. Бәлки, бик үк белеп тә бетермиләрдер. Әмма алар тик утырмый, өйрәнәләр, тыңлыйлар. Иң мөһиме: үз телләрен саклау теләге бар. Бу мәсьәләдә республиканың да ярдәме сизелә. Кыскасы, шартлар бар, ә нинди телдә сөйләшергә кирәклеген һәркем үзе хәл итә. Без, мәсәлән, өйдә өч телдә сөйләшергә тырышабыз. Әмма гаилә биргән югалмасын өчен мәгариф өлкәсендә яңалыклар өмет итәбез. Милләтнең бөтен көче, тамырлары телгә барып тоташа. Татар кешесе нинди дисәгез, иң элек намуслылык һәм бераз гына үзсүзлелек сыйфатлары искә төшә.

Киләчәк

Зур өметләр баглап

Айдар ШӘЙХИН, Татар китабы йорты һәм «Гыйлем» берләшмәсе җитәкчесе:
– Татар фәне – ике мәгънәдә кулланыла торган төшенчә. Бер яктан, без татарларны өйрәнә торган фәннәрнең җыелмасын шулай атыйбыз. Хәзерге вакытта аны күбрәк шушы мәгънәдә кулланалар да, татар фәнен татароведение, татаристика дип атыйлар. Икенче яктан, татар фәне – татар галимнәре тарафыннан тудырылган яки татар телендәге фән. Беренчесе бездә азмы-күпме бар, икенчесе юк дәрәҗәсендә.

Хәер, соңгы елларда татаристика да шактый авырлыклар кичерә. Әйе, казанышларыбыз җитәрлек. Шул ук вакытта милли кадрлар мәсьәләсе дә кискен тора. Алар әзерләнәме, әзерләнсә, киләчәктә перспективалары ни дәрәҗәдә һәм башка сораулар күп очракта ачык кала. Бу өлкәдә Бөтендөнья татар конгрессы күп нәрсәне эшли алыр иде.

Элек конгресс һәм башка оешмалар тарафыннан барлыкка китерелгән татар галимнәре корылтайлары узган. Дөньяның төрле почмакларында яшәүче һәм төрле өлкәләрдә хезмәт иткән татар галимнәрен берләштерә торган оешма яки шушындый җыелу формалары хәзер дә булырга тиештер.

Конгресс төрле төбәкләрдән университетка абитуриентлар туплый, аларны татар теле юнәлешендә укыта, бу – бик зур эш. Әлеге юнәлеш тагын да активлашсын иде. Ул студентлар киләчәктә нәрсә белән шөгыльләнергә тиешлеген дә уйларга кирәктер дип саныйм.

Шунысы да бар: яшь галимнәрнең иҗтимагый оешмаларга өмет баглавы – катлаулы мәсьәлә. Чөнки иҗтимагый оешма нәрсә бирә ала? Фән белән шөгыльләнгән кешегә гомумән нәрсә кирәк? Барыннан да бигрәк фәнни эшчәнлегенә матди ярдәм кирәк. Моны грант, стипендия, максатчан программалар аша чынга ашырып була. Татарларны өйрәнү юнәлешендә шундый грантлар булса, күп кешегә мотивация бирер иде.

Татар галимнәрен күрсәтү, таныту эшен дә алып барырга иде. Без бит татар галимнәренең күпчелеген белмибез дә. Татар дөньясын гыйльми һәм фәнни дөнья буларак таныту кирәк. Ә бу һаман да җитми. Заманында «Гыйлем» проекты шушы максаттан барлыкка килгән иде инде. Ул фәнне яшәтү һәм татар телен фән теле итеп күрсәтү юнәлешендә эшли. Хәзерге вакытта Бөтендөнья татар яшьләре форумының «Ачык университет» проекты уңышлы бара. Бу – безнең перспектива һәм үсешнең, миңа калса, бердәнбер адекват формасы. Ләкин әлеге дә баягы һәртөрле проектларга стимул да кирәк.

ГАЛИМ НАДИР БАҺАВИЕВ:

«МИН ДЕТАЛЬ ИСЕМНӘРЕН ҺӘРВАКЫТ ТАТАРЧА ЯЗАМ»

Фән тел үсешенә ничек тәэсир итә ала? Аның өчен нинди шартлар тудырырга кирәк? Һәр татар кешесе бу юнәлештә нәрсәләр эшләргә тиеш? Татар өчен таяну ноктасы кайда? Галим Надир БАҺАВИЕВ белән әнә шул хакта сөйләштек.

:: Фәндә татар телен ничек популярлаштырып була?
– Фәндә татар телен түгел, ә «Татар дөньясында фәнне ничек популярлаштырып була?» дигән сорауга җавап эзләргә кирәк, минемчә. Мәсәлән, Татарстан Фәннәр академиясе я лингвистика, я археология, я нефть белән генә шөгыльләнә. Химия, Физика, Биология, Санак фәне, Космонавтика, Робототехника институтларын ачып, һәрберсендә үз фәнни журналларын алып барырга кирәк. Татарча мәкаләләр бастырган галимнәргә йөз меңләп я миллион сумлы премияләр ясау, бәйгеләр үткәрү дә стимул булыр иде. Шул рәвешле яшь галимнәрне үстерсәк, татар телендә фән үсә башлар. Тукай сүзләре белән йомгаклап куйсак:

«Яхшы булыр тапшырсак без дөньяларны
Абразауный егетләргә тәмам имди.
Барып керик хөрриятнең кочагына,
Тәрәкъкыйнең күкләренә очмагына;
Бу егетләр безне дөнья оҗмахына
Кулдан тотып җитәклиләр, белең имди!»

:: Хәзерге вакытта татарча фәнни эшләр эшләнәме соң?
– Юк шул. «Фәнни Татарстан» журналын карасак, бер мәкалә дә фәнгә бәйләнмәгән.

:: Аның сәбәпләре нидә?
– Галим яки инженер, фән я техника белән шөгыльләнгәндә, кешелекне алга алып бару һәм үз даны турында уйлый, әлбәттә, акчалата нәтиҗәсе булыр дип тә өметләнә. Син нинди телдә эшлисең, шул халыкка хезмәт итәсең. 1992 елда суверен республика статусын алгач, бездә үз фәнебезне алга алып барырга мөмкинлекләр туды. Мин бизнесның күп кенә өлкәләрендә милләттәшләребезнең татарча гына сөйләшкәнен ишетә идем. Хәтта сырхауханә белән хастаханәләрдә дә шәфкать туташлары белән докторлар татарча сөйләшә иде. Димәк, татарлар башка халыкка ошыйм дип түгел, ә үз халкыма ошыйм дип, эшне я фәнне татарча алып барса, бу хәрәкәт, һичшиксез, уңай нәтиҗәләргә китерер. Мин, мәсәлән, үзебезнең конструкторлар бюросы өчен модельләр һәм сызымнарны ясаганда бөтен деталь исемнәрен татарча язам. Күптән түгел криптәнкә – криптоакча барлыкка китердем. C++ телендә программалаштырырга туры килсә дә, программа эчендә комментарийлар, переменныйлар, массивлар, файллар исемнәре татарча язылган. Соңгы вакыйгалар аркасында милли үзаң үсә, татар телен белү популярлаша бара. Ниһаять, бу горурлык һәрберебездә уянгач, космоска да үз телебездә чыгарбыз.

«Татар-информ»

:: Фәндә кулланылмагач, татар теленең киләчәге бармы?
– Фән белән үз телендә шөгыльләнмәгән халыклар юкка чыга бара. Мин техника белән шөгыльләнгәч, бик күп сүзләрне инглизчә язарга мәҗбүрмен. Татарлар энкодерлар ясамый, звездолетлар турында аз уйлый. Мин аның турында күп уйлагач, звездолетны йолдызат дип атадым. Бәлки, бу сүз сүзлеккә керер. Шулай итеп, әкренләп, мәкалә, китап, фильмнар, музыка аша тел үсәр дип өметләнәм. Ә татар теле ул кристалл кебек төгәл. Татар телендә уйлаганда, фәнни, я булмаса, инженер концепцияләре башта тиз әзер идеягә әверелә.

:: Бәлки, татарча фәнни эшләр дә бардыр, без белмибез генәдер...
– Юк. Франциядә башка Татарстан юк, Көньяк Америкада да Казан юк. Бездә бер генә Казан, бер генә Татарстан, бер генә Әстерхан, бер генә Кырым, бер генә Себер бар. Беркем дә яшерен рәвештә татар телендә квант санакларны ясап утырмый. Бездә без генә бар.

:: Татар булмаган өлкә юк, диләр, дөресме? Ә сез кайсы өлкәдә?
– Һәр өлкәне тикшереп карамадым, әмма әле генә бер фантастик әсәр өчен идея туды. Бөтен дөньяда татардан башка бөтен башка халыклар аңгырага әверелде ди. Ул чакта татар халкы берләшеп, «Боинг» кебек очкычларны төзи алырмы? «Оптоволоконный лазер»ларны ясармы? Миллиард транзисторлы процессорлар җитештерерме? Һава торышын күзәткән, я GPS кебек иярченнәрне төзеп, ракеталарда космоска җибәрерме? Протеиннарны урнаштырып, даваны синтезлаштыра алырмы? Атом-төш реакторларын төзерме? Супертанкерларны төзи һәм йөртә алырмы? Ә алмасак, дөнья нинди дәрәҗәгә төшәр? Мин тасвирлаган һәр өлкәдә бер татар гына булырга тиеш түгел, ә бу катлаулы җиһазларны без халык буларак төзи белергә һәм төзергә тиеш. Бу катлаулы белемнәрне туплап, үз җиһазларыбыз белән дөнья күләмендә экономик ярышта җиңәргә тиешбез.

Мин – ракеталар конструкторы. Казанда үз конструкторлар бюромны ачып, башта металл белән бастыручы 3D-принтерларны ясыйм, ә аннан инде Кама Тамагыннан җибәрелә торган бер баскычлы, күп кулланышлы орбиталь ракеталарны төзи башлыйм.

:: Бөтендөнья татар конгрессы татарга таяну ноктасы була аламы?
– Татар халкында күп таяну нокталары бар һәм тагын да күбрәк була ала. Себер, Казан, Әстерхан һәм Кырым татарлары белән тагын да зуррак конгрессны булдырырга була, конгресс бу өлкәләр аша татар туризмын үстерә ала, телләрне уртак кагыйдәләргә китерергә булыша ала, татар телендә генә алып барылган технопарк я фән үзәген оештыра ала. Идеяләр күп, идарә итүчеләрнең чын максатлары татар халкын үстерүгә юнәлгән булырга тиеш. Хәзерге вакытта күп халыклар нинди юл белән барырга белми һәм безнең бөек халкыбызның бу катлаулы чорда хәтта бөтен дөньяга юл күрсәтә алырлык мөмкинлегебез бар.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ТЕЛ БЕЛӘН САНЛАШУ

Киләчәгебез турында әйткәндә, мәгариф һәм цифрлы даирә турында телгә алмыйча мөмкин түгел. Беренчесе нигез булса, соңгысы – замана таләбе. Бу юнәлешләрдә татар мохитенә урын бармы?

tatarstan.ru

Рашат ЯКУПОВ, татар теле укытучысы, активист:
– Хәзерге көндә татар теле киләчәге миндә зур борчылу хисен уята. Өметле булырга тырышам, ләкин чынбарлык тенденция хәлне яхшы якка алып бармый дип уйлыйм, – ди. – Татар телендә тулы канлы мәгариф системасы эшләмәгән хәлдә телнең киләчәген позитив фаразлап булмый. Проблемалар арасында мәктәпләрдә татар теленең укытылышын атар идем, хәзер ул бик аз күләмдә укытыла, үземнең тәҗрибәмә күрә телне атнасына 2 сәгать кенә укытканда, зур уңышка ирешеп булмый, минималь аралашу күнекмәсен генә биреп була.

Укытучыны төрле предметларны татар телендә укыту мәсьәләсе дә борчый.

– Моның өчен заманча программалар, видеодәресләр, тулы платформалар кирәк. Үземнең бер укучым бер мәктәптә физика фәнен татарча укыта башлагач, гел яныма килеп зарлана иде, чөнки материаллар юк, заманча программалар, татарча видеодәресләр һәм башка кирәкле контент юк, – ди Рашат Якупов.

Әмма өмет очкынын кабызып җибәрә торган күренешләр дә юк түгел.

– Мәгариф өлкәсендә соңгы елларда уңай үзгәрешләр дә бар, мәсәлән, үземнең дә кулым тигән «Сәлам» дәреслеге чыкты, «Адымнар» күптелле мәктәпләре эшли башлады. «Адымнар»ның эшчәнлеген мин бик югары бәяләр идем, җитәкчелек тә, укытучылар да – милли җанлы кешеләр, бик тырышып эшлиләр. Ләкин андый мәктәпләр берничә генә түгел, Татарстанның һәр районында булырга тиеш дип саныйм. Татар мәктәпләрен дә заманча җиһазландырып, укытучыларга лаеклы шартлар тудырып, алдынгы мәктәпләр итү программасы булырга тиеш.

Дәүләт имтиханын татар телендә тапшыра алмауны да әйтми булмый. Бу – гомумән, татар телендә белем алуга зур киртә булган һәм татар мәгариф системасының эзлеклелеген бетергән күренеш, – ди Рашат Якупов.

«Туган телдә аралаша торган буын булсын өчен нишләргә?» – дигән сорауга Рашат:

– Балалар, яшүсмерләр, яшьләр татарча аралашсын өчен, заманча контентның татарча күп булуы кирәк: «Ютуб»та татарча заманча мультфильмнар, фильм, яшүсмерләр сериаллары, Голливуд сыйфатында төшерелгән фильмнар, видеоуеннар һәм башкалар. Кызганыч, әлегә кадәр бу өлкәдә зур кытлык сизелә. «Шаян ТВ» кебек уңай проектлар бар, алар бик шәп эшли һәм тырыша, ләкин бу тырышлыклар гына аз, медиа киңлектә татар контенты югалып кала, – дип җаваплады.

Телне өйрәтүдәге заманча алымнар куллану җәһәтеннән дә Рашатның үз фикере:

– Телне өйрәтүгә килгәндә, чит тел укытуда коммуникатив методика һәм алымнар куллануны арттыру мөһим. Татар телен уку укучылар тарафыннан кызык, рәхәт процесс булып кабул ителергә тиеш, моның өчен күпләп уеннар, активитилар, мультфильмнар, мавыктыргыч видеодәресләр, видеоуеннар һәм интерактив программалар кирәк. Татар теле мәктәпләрдә барысына да укытылмый икән, безнең бурычыбыз шундый шартлар тудырырга: барысы да теләп аны сайласын, барысы да татар теле кабинетына керергә теләсен.

Цифрлы хыяллар турында исә яшь буын вәкиле – **Ясалма интеллект проектлары җитәкчесе Тимерхан ШӘЙХЕТДИНОВтан** сораштык.
– Гомумән, минем остазым – википедист, синхрон тәрҗемәче Фәрһад Фәткуллин әйтмешли, татар теле исән калсын, киләчәге булсын өчен аның интернет мохитендә дә булуы, яшәве мәҗбүри. Хәзерге көндә көчле мәгълүмати чорда яшибез һәм ул мәгълүмат виртуаль дөньяда да бара. Интернет киңлегендә барган тормышыбыз татар телле контент белән баетылырга тиеш.

Киләчәгебез дигәндә, татар телен хәзер аеруча үсеш алган юнәлешләрдә күрергә телим. Социаль челтәрләрдә татар телле интерфейслар куллану, хәзер гамәлдә булган интернет ресурсларны үстерү, актуаль мәгълүмат белән тутыру, башка телләрдә булмаган безгә хас контент чыгару – хыяллар шул. Соңгысы дигәндә әле өйрәнелмәгән, уникаль чыганакларны күздә тотам. Гомумән, татарның фәнни, фәлсәфи, иҗтимагый фикерен өйрәнеп, тәкъдим итәсе иде. Иң мөһиме – аның белән бүлешү һәм башкалар өчен дә ачык итү.

Кешенең тормышы көннән-көн цифрлы чынбарлыкка чумып бара. Шуларны күзәтеп торабыз. Хәзер мета-галәм, VR-чынбарлык дигән сүзләр еш ишетелә. Менә шуларга да татар телен кертү ысулларын табасы иде. Аннан исә бөтендөнья аудиториясе алдында аны тәкъдим итү дә бар бит.

Татар цифрлы даирәдә үзенең мохитен табарга тиеш. Гомумән, цирфлы даирәдә татар телен куллану кешенең көн тәртибендә торсын. Шул ук Windowsның татар теллесен куллану, «ВКонтакте»дагы «бит»не татарчага күчерү, татарча клавиатура кулланып язу – болар да телебезнең яшәешен арттыра. Социаль челтәрләрдә мәгълүмат белән бүлешкәндә дә татарча бүлешик.

Ясалма проектлар белән шөгыльләнгәч, татарча сөйләмне аңлый һәм сөйләмне булдыра торган ясалма интеллектны барлыкка китерү буенча зур хыялыбыз өстендә эшлибез. Әйтик, «Сүрия, бишкә бишне кушкач, ничә була?» дигән сорауга, татарча итеп «ун» дип җавап бирә торган интеллект булса, ничек шәп бит, – диде ул.

Милли сәнгатьнең киләчәге өметле булсын өчен, бүген без нәрсә эшли алабыз? Һәм нәрсә эшләргә тиешбез? Яшь иҗатчылар белән әнә шул сорауларга җавап эзләп карадык.

Сәнгатьнең жанрлары төрле һәм күп булган кебек, бүгеннән үк хәл ителергә тиешле мәсьәләләр дә җитәрлек. **Шагыйрь Булат ИБРАҺИМ** шуларның берничәсенә тукталды.
– Сәнгатьнең төрләре, жанрлары күп бит аның. Болар барысы да милләткә хезмәт итү белән бергә аңа каршы да эшли ала торган көч булып тора. Сәнгатькәрләр үзләренең әсәрләрендә безнең менталитетны, гореф-гадәтләрне, тарихны бозмыйча, читкә китмичә күрсәтә алса, бу – милли хәзинәбез өчен зур уңыш. Әмма шул ук сәнгатькәрләр халкыбызны дөм пычратып, ялган белән сугарылган әйберләр тудырсалар, бу инде – милли сәнгатебезгә зыян салу. Бу беренче иде. Икенчедән, хәзерге заманда һәрбер эш зур акча сорый. Әдәбият белән җыр сәнгатендә иҗат итү өчен чагыштырмача зур матди чыгымнар кирәкми. Шуңа күрә бездә хәзер һәрбер кеше язучы һәм җырчыга әйләнде. Бу сыйфатка тискәре йогынты ясый һәм ясаячак та. Ләкин шул ук вакытта татар җыр сәнгате, барыбер үз аягында нык торып, җырчыларга табыш китерүне туктатмый. Ә инде опера, кино, балет, театр дәүләт яки берәр оешма ярдәменнән башка гына тамашачы хозурына килеп ирешә алмый. Зур чыгымнар, профессиональ команда, айларга, елларга сузылган әзерлекләр. Ләкин менә бу сәнгать төрләре халыкның барлыгын, зурлыгын күрсәтеп торучы төп билге дияр идем мин. Үз операсы, үз балеты булган халыкның киләчәге бар, – диде ул. – Өченчедән, милли сәнгатьне үстерү өчен Мәдәният министрлыгы булу гына җитми. Махсус «Татар милли сәнгать фонды» оештырылса, шәп булыр иде. Яхшы пиар-менеджерлар һәм продюсерлар әзерләргә кирәк. Күп кенә татар киноларын эзләп табып булмый, ә рус һәм чит ил сериалларының рекламасы һәрбер сайтта, һәрбер мобиль кушымтадан «сикерә» дә чыга. Сәнгать башка хезмәт профессиясе кебек үк акча да китерергә тиеш. Гел дәүләт хисабына гына яшәү дөрес түгел. Язучылар берлеге, Композиторлар берлеге, Рәссамнар берлеге, Фотографлар берлеге, әле саный китсәң, тагын бардыр. Алар барысы да – дәүләт хисабында утыручы иҗтимагый оешмалар. Көннәрдән бер көнне Мәдәният министрлыгы: «Безнең сезне асрап торырга акчабыз юк, үзегез азык эзләгез», – дисә, хәлләр мөшкел булачак бит.

Композитор Миләүшә ХӘЙРУЛЛИНА фикеренчә, бүген бөтен игътибар эстрада сәнгатенә юнәлтелгән, һәм бу киләчәккә бик үк уңай йогынты ясамаячак.
– Бүген без киләчәк өчен нәрсә эшли алабыз? Беренчедән, гасырлар буе тупланган мирасны саклап, үзебез белән киләчәккә илтә алабыз. Икенчедән, бүген татар мәдәниятен эстрада сәнгате белән генә чиклиләр кебек. Аңа игътибар артык зур. Ничек кенә карасаң да, бик җиңел жанр бит ул. Ә бит безнең зур, җитди жанрларыбыз да бар. Алар кешене, чын мәгънәсендә, рухи яктан баета. Бүген безгә менә шушы юнәлешне халыкка кызыклы итү өстендә эшләргә, башны шул якка борырга кирәк. Һәм, әлбәттә, бөтен өмет – яшьләргә. Киләчәк өметле булсын өчен, без аларга ышанычыбызны арттырырга, фикерләрен, идеяләрен тыңларга, ярдәм итәргә һәм, иң мөһиме, яшьләргә югары белем алу өчен бөтен мөмкинлекләрне тудырырга тиеш. Дөнья стандартлары белән тәңгәлләшергә телибез икән, аларны читтә укудан курыкмаска кирәк. Тиешле юнәлеш бирсәң, укымышлы яшьләребез милли мәдәнияткә, аның дәрәҗәсен күтәрү хакына хезмәт итәчәк, – диде яшь композитор.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6640 данә
Гомуми тираж – 16052 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 309

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+